Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 30 (1446) 4 август 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

2

Биш ел элек үк Чистай районындагы Яуширмә авылы юлларын һәм Г.Исхакый музеен яңартырга вәгъдә бирсәләр дә, анда әлегәчә берни үзгәрмәгән.


6

Татарстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллинга бүген 80 яшь.

8-9

Революциягә кадәр татар дөньясының аерым бер мәдәни үзәге булып торган Оренбург каласында барча зыялылар күренекле Дәрдемәнд учагы янына туплана.

Күркәм йолаларны юлдаш итсәк, Кальбебез дә һәрчак хушланыр!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Идел буенда 29 июль көнне булып узган давыл вакытында Яшел Үзән, Биектау, Питрәч районнарында 12 мең кеше утсыз калды, 14 кеше һәлак булды, шуларның 4 се – Татарстаннан.

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов давыл вакытында һәлак булган гаиләләрнең кайгысын уртаклашты.

- Көчле давыл вакытында Мари Эл республикасындагы Яльчик күлендә көймә капланган һәм 8 кеше вафат булган, араларында 3 бала да бар.

- 30 июль төнендә Украинаның пилотсыз очкычлары Мәскәү-Сити манараларына һөҗүм иткән, әмма зыян күрүчеләр булмаган.

- Ростов өлкәсе губернаторы Василий Голубев хәбәр итүенчә, Таганрог шәһәре үзәгендәге «Чехов сад» кафесы янына ракета төшеп шартлаган, 12 кеше зыян күргән.

- Узган атнада «Татмедиа» акционерлар җәмгыяте хезмәткәрләре һәм татар матбугатын сөючеләр «Шәһри Казан» кушымтасы булган «Язмыш» газетасының 2 яшьлеген билгеләп үтте.

- Теләче районының тарихи яктан бик гыйбрәтле – 1708 елның гыйнварында фетнәче татар крестьяннары Петр патша юллаган ике җәзачы полкны биклап тоткан Баландыш авылында «Түгәрәк уен» фестивале гөрләп үтте.

- Татарстанда Норлат, Тәтеш, Чүпрәле, Бөгелмә районнары игеннәрдән 30-36шар центнер уңыш алып, алдынгы сафларда бара.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

4 август – шагыйрь, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Равил Габдрахман улы Фәйзуллинга 80 яшь (1943).

Туган өйдә күргән төш
Шундый матур төш!
Бөтен җир гел –
чәчәк тә гөл!
Чишмә дә инеш!
Һәм шунда...
мин, имеш!
...Айны урак итеп гөл кистем.
Чүмеч йолдыз белән су эчтем!

СЫНАМЫШЛАР

- 7 августта җылы һәм аяз булса, кыш салкын киләчәк, яңгыр яуса – җылы һәм карлы булачак.
- Августта каенда сары яфрак күп булса, көз иртә килә.
- Коеп яуган яңгыр тиз туктый.
- Яңгыр җиргә тиз сеңсә, көннәр яңгырлы була.
- Кичтән томан тө

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 54 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 47 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 53 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **28 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **11 августта 15 сәгать 25 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(1-8 август)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 17 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

ИСХАКЫЙ ВАТАНЫНДА



22 июль иртәсендә сәгать дүрттә үк сикереп торылды. Ихатага чыгып, баскычта утырам, җанны нидер тырный. Хәтер казанын кырам, йә Ходаем, бүген эткәйне җирләгәнгә 25 ел бит! Дога көтеп ятуыдыр инде, әмма аны үткәрү әзерлексез булмый, димәк, башка көнгә күчерергә кирәк...

Ә җан дигәне барыбер тынгы белми. 22 июль – шәхсән Тукай үзе «милләт юлбашчысы» дип олылаган каләмдәшебез Гаяз Исхакый вафат булган көн дә. Быел аның вафатына 69 ел үткән. Нинди галәмәт беләндер, мин фәкыйрегез ул китеп барасы елда дөньяга аваз салганмын. Исхакыйның милләтебезне хөр итеп күрергә хыялланган барча фикерләре белән ризалашам. Тик ни үкенеч, еллар буе суза-суза 15 томлыгын дөньяга чыгарсак та, аның рухын, изге хыялларын милләт күңеленә сеңдерә алмадык шул. Хөрлек турында хыялланып, 1999 елда Гаяз аганың кече ватаны булган Яушырмәдә аңа багышланган музей комплексын ачуга ирештек тә, тиз арада ул авылга юлны бикләп куйдык. Ә югыйсә...

1999 елның 22 июлендә Татарстанның тәүге Президенты М.Шәймиев катнашында музей ачкан чакта республиканың барча районнарыннан 5 меңгә якын милләттәшебез җыелып килгән иде. Улчактагы Мәдәният министры, үзе дә Чистай районының шушы авылында туып-үскән Илдус Тарханов барча халык алдында Президент кул куйган фәрманны да укыды: «Һәр ел саен Чистай районының Яушырмә авылында Гаяз Исхакый укулары, ә Лаеш районында «Каравон» бәйрәме үткәрүне традициягә әверелдерергә һәм әлеге чаралар өчен ел саен 500 мең сум күләмендә акча бүлеп бирергә». Яушырмәгә барча министрлар һәм район башлыклары гына түгел, дистәләгән язучы һәм шагыйрь, барча театр һәм сәнгать коллективларыннан йөзәрләгән күренекле артист, милли мәктәпләрдән йөзләрчә мөгаллимнәр җыелышкан иде, барчабыз сөенештек. Президент тора-бара Исхакый музеен киңәйтеп, ачык һавадагы татар авылы күренешен сафка бастыру турында да сүзләр алып барды. Нигезе дә булдырылган шикелле, музей ихатасыннан читтәрәк, Бахта инешенең аръягында, малай чакта Гаяз Исхакый да барып йөргән, аннан гаиләләре өчен су ташыган Казый чишмәсенә асылмалы күпер дә корып куелган иде бит...

Берничә ел буе Исхакый укулары шаулап үтте әле. Анда Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев кебек даһиларыбыз белән әңгәмә корып алулар гаять җиңел, аннары – иң мөһиме – әлеге бәйрәмнәрдә Камал театры артистлары нинди дә булса спектакльдән зур-зур күренешләр уйнамыйча калмый иде. Шуңадырмы, тәүгерәк елларда кунакларның саны 2 мең чамасыннан кимемәде. Аннары Исхакый укуларын үткәрүгә акча бүлеп бирүне кисәк туктаттылар. Камал театры директоры Шамил Закиров, төрле оешма җитәкчеләре белән сөйләшеп, бер-ике ел чамасы иганәчеләр тапты, ләкин, үзегез беләсез, симергән тавыкларның арты бөрешә бит. Шуннан соң Исхакыйны туган көнендә искә алу йоласын Чистай мәдәният йортына күчерделәр. Тора-бара анысы да сүнде. Менә соңгы биш ел дәвамында Яушырмәгә мактанып телгә алырлык бер генә җитәкче дә, хәтта язучылар да килеп карамаган. Ә шул ук вакытта Лаештагы «Каравон» да, Державин укулары да һәр ел саен гөрли. «Каравон»ны котлау өчен һәр ел саен республика җитәкчеләре үзләре килми калмый, аның бюджеты да ун миллион сум чиген узып китте бугай...

Исхакый укуларын кире кайтару, бөек әдипнең хөррият рухын милләттәшләребезнең җанына сеңдерү өчен көрәшмәдек түгел, тырышып карадык без. Исхакый музееның ташландык хәлгә килүе, Яушырмәгә алып бара торган юлларның Украинадагы шикелле җимерелеп бетүе турында «Мәдәни җомга» газетасы кат-кат язып чыкты. Әлеге музейның аяныч хәлен тасвир итсеннәр дип, ике мәртәбә «Татарстан – яңа гасыр» телевидениесенең аерым бригадасын, ахыр чиктә инде Дәүләт Советы депутатларының махсус мәдәният комитеты әгъзаларын да алып бардык. Халык игътибарын җәлеп иткәч, республиканың иң югары җитәкчеләре музейны һәм Яушырмә юлларын сафка бастыру өчен 39 миллион сум акча бүлеп бирергә вәгъдә итте. Ләкин, үч иткәндәй, нәкъ шул җәйдә Исхакый музееның утарында 20 ел буе басып торган кое, мунча, келәт биналарын ут төртеп яндырдылар һәм вәссәлам. Ул юату белән афәттән соң биш ел вакыт үтеп китте инде, тик музейны төзекләндерү өчен бармакка-бармак сугып караучы да табылмады...

22 июль иртәсендә 8 сәгатьтә мин фәкыйрегез янә Яушырмә уртасындагы музей каршында тора идем инде. Исхакый бюсты куелган кирпеч пьедестал берничә урыннан ярыла башлаган иде, шуны былтыр коңгырт төстәге плиткалар белән тышлап чыкканнар, шуннан ары берни үзгәрмәгән. Музейдагы экспонатлар да, тирә-юнь дә һичбер шиксез яңартуны, хәтта заманча җиһазлар белән тулыландыруны көтә. Исхакый һәм аның якыннарының музей диварларына куелган фоторәсемнәрен кеше күзенә күренерлек итеп зурайтасы, аларны фотошоп ысуллары белән чистартасы иде. Анда гарәп хәрефләре белән язылган һәм үз заманы өчен бик әһәмиятле булган афишалар, китап тышлыклары, безнең өчен үтә кадерле булган Милләт Мәҗлесенең 1917 елда игълан ителгән хөрлек карарлары, Исхакыйның шәхси хатлары санап бетергесез. Янәшәгә аларның кириллицага күчерелгән аңлатмаларын да эләргә бик вакыт...

Казан-Әлмәт трассасыннан аерылып, Яушырмәгә алып бара торган юлны юл дип санарлык та түгел. Мин фәкыйрегез барган шимбә көнне дә Исхакый музена Казаннан бер төркем сәяхәтче килгән иде. Шушы ук көнне Яушырмә мәктәбенең кайсыдыр чыгарылышы үзләренең юбилеен билгеләр үтәргә дип авылга җыелган да, күмәкләшеп Бөек Исхакый рухы каршында баш ияргә килгән. Бер көн дәвамында, ким дигәндә, кырыктан артык кунак. Тик юл дигәне – мәхшәр. Җөмһүриятебез җитәкчеләре Яушырмә авылын 5-6 ел элек үк Мари-Эльнең Звенигово ит комбинатына сатып җибәрде. Бүген авылда Хузангай исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять эшләп ята. Кайбер басудагы игеннәрне ура башлаганнар. Чит-ятлар хуҗа булып алгач, Яушырмәдәге ындыр табагы да, терлек фермаларының яртысы да юкка чыккан инде. Ындыр табагы булмагач, сугылган ашлыкны да басудан Мари-Эльдәге терлекләрне симертү цехларына турыдан-туры гына озаталар. Чит хуҗага синең татар авылындагы урамнар да, Исхакый музеен дә, Яушырмәгә алып килә торган юлларның да кирәге юк. Байлар кесә-сандыклары тулганчы татар авылын талый-савачак та, авыл коргаксып калгач, яңа табыш урынына табан ялтыратачак. Ә хурлыгы халыкка һәм җөмһүрияткә. Мәскәү программа артыннан программа игълан итә. Татарстан хөкүмәтенең дә барча җирлек үзәкләренә илтә торган юлларны асфальтлаштырып бетерү турында карар игълан итүе истә. Тик ни гаҗәп – Яушырмәгә юлларын төшләренә дә кертеп карамыйлар. Халкы – татар, ә байлыгына күрше республикадагы эшкуарлар хуҗа. Менә шулай – үз илендә ятим булып яши ул Яушырмә. Бар гомерен газиз милләтенең хөрлеге һәм бердәмлеге өчен багышлаган Гаяз Исхакый да һаман үги. Акчага табынучы хуҗалар идарәсендә гомер сыктаучы коллар халәте бу.

23 июль, 2023.

Иш янына куш

27-28 июль көннәрендә Санкт-Петербургта икенче мәртәбә Россия-Африка саммиты үтте. Анда Африканың 49 иленнән вәкилләр (17се – дәүләт җитәкчесе) катнашуы турында әйтелде. Чара югары дәрәҗәдә һәм күтәренке рухта узды кебек. Саммит кысаларында үткән Икътисади-гуманитар форумның пленар сессиясендә РФ президенты В.Путин үзе катнашкан һәм, Россия белән Африка илләре арасындагы бәйләнешларның сәяси, икътисади, гуманитар өлкәләрдәге торышы вә үсеш перспективаларына югары бәя биреп, чыгыш та ясаган. Саммитның эш нәтиҗәләре буенча Йомгаклау декларациясе һәм башка документлар кабул ителгән, чара кысаларында төрле форматта дистәләрчә килешүләр дә төзелгән. РФ президенты һәм Африка илләре лидерлары, шулай ук, Украина тирәсендәге вәзгыятьне җайга салу буенча июньдә Санкт-Петербургка соңгылары алып килгән «тынычлык инициативасы»н дәвам итеп, кабаттан да сөйләшкән. Ә аңа кадәр В.Путин, аларның һәркайсы белән аерым-аерым очрашып, ике яклы сөйләшүләр дә үткәргән. Рәсми хәбәрләргә караганда, саммит үзара аңлашу рухында үткән.

Игътибарны бу саммит белән бәйле реаль хәлләрнең сәяси, икътисади һәм кайбер башка якларына да юнәлтик. Әйе, ул, хактан да, глобаль тетрәнүләр чорында һәм көн кадагына туры китереп үткәрелде. Саммит тирәсендәге сәясәт уены әле аңа әзерлек чорында ук башланды. Россиядә әчке кулланышка исәп тотып әзерләнгән хисләр ташкыны исә саммит алдыннан дөнья күргән мәкаләләрнең исемнәрендә үк чагылыш тапты. Аларның кайберләренә игътибар итик: «Путин не поедет в Африку. Африка приедет в Россию», «В Кремле призвали осудить линию Запада по давлению на страны Африки», «Запад упустил большое возвращение России в Африку» һ.б. Ә төп фикерләрне «кара кыйтга» халкына да җиткерү ниятендә, саммит алдыннан Африка мәгълүмат чаралары өчен «Россия и Африка: объединяя усилия для мира, прогресса и успешного будущего» дигән мәкаләсен инде Путин үзе тәкъдим иткән. Саммитта исә лейтмотив булып күбрәк, Көнбатыш – явыз, ә без – яхшы, Россияне изоляцияләү идеясе барып чыкмады, кебек фикерләр яңгыраган. Күпполярлы яңа дөнья системасында Африка төп партнерларның берсе булырга тиешлеге, ә Африка Берлегенең «зур егермелек» төркеменә әгъза итеп алу турында карарны инде G20 нең сентябрьдә Яңа Дәһлидә узачак саммитында кабул итү кирәклеге турында да әйтелгән.

Дөнья матбугаты исә әлеге саммитка карата башкача фикердә тора. Беренче көн нәтиҗәләре буенча Bloomberg, әйтик, Украинада озакка сузылган конфликт фонында саммит Кремльнең Африкага йогынтысы кимүен күрсәтә, дип язган. Мәсьәләнең икътисади ягы да үзенчәлекле. Әйтик, Африка иләренең 2022 елда Кытай белән тауар әйләнеше 282 миллиард доллар булса, Россия белән ул нибары 18 миллиард доллар тәшкил иткән. Мәскәүнең ярлы илләрне акча белән үзенә лояль итүе (аның Африка илләренә 23 миллиард долларлык әҗәтләрен гафу итүен генә алыйк) һәм, шул рәвешле, БМО ГА утырышларында мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә, аларның аны яклап тавыш бирүенә исәп тотуы да сер түгел. Менә бу саммитта да (ә ул, Мәскәү ашлык килешүеннән чыгу сәбәпле, Африка илләре ач калган чорда үтте) В.Путин Россиянең Украина ашлыгын капларга әзер булуы, ә иң мохтаҗ 5 илгә 25-50 меңәр тонна ашлыкны бушка бирергә дә җай чыгуы турында белдергән. Әмма Африка илләре ашлык килешүен яңартырга чакырган. Африка Берлеге рәисе Азали Ассумани, азык-төлеккә бәянең нык артуы сәбәпле, ашлык Россиядән дә, Украинадан да килүен теләүләре турында белдергән. Хәтта Мәскәүгә лояль саналган КАР президенты Сирил Рамафос та бу җәһәттән, без монда хәер сорашу өчен килмәдек, шуңа күрә ашлык килешүенең үтәлүен таләп итәбез, без Кара диңгезнең дөнья базарлары өчен ачык булуын телибез, дип әйткән.

Гомумән алганда, Россия-Африка саммитын бүген геосәяси нигездә формалашып килә торган «Глобаль Көньяк» проектының бер элементы, дип карарга кирәктер. Чөнки «Глобаль Көньяк», асылда, БРИКС, ШОС кебек оешмалар аша формалаштырыла. Әлбәттә, Россияне авырлык белән генә «көньяк» категориясенә кертергә буладыр. Әмма, дөнья тотучыларның сәясәт коралы һәм Көнбатыш белән Кытай арасында буфер зонасы итеп формалаштырылган берәмлек буларак, геосәясәттә аңа андый үзенчәлекле функцияләрне дә үтәргә туры килә. Татарда, иш ишен ерактан күрә, дигән әйтем бар. Цивилизацион яктан РФ, Африка илләре кебек үк, үсеп килүче дәүләтләр рәтенә керә. Мәгәр, сәяси системасы ягыннан да ул алардан әлләни ерак китмәгән. Шулай итеп, иш янына куш, дигәндәй, Көнбатышка җитди геосәяси альтернатива буларак, «Глобаль Көньяк» формалашып килә. Дөнья тотучылар омтылган яңа дөньяви тәртип тә, мөгаен, алар арасында яңа мөнәсәбәтләр кагыйдәсе буларак урнашыр.

Фоат УРАЗАЙ.

Сөйләшүләргә әзерлек арта

Әлегрәк, Украина белән сөйләшүләрдән мәгънә юк, океан артыннан ни әйтсәләр, ул шуны эшли дип, тәкъбирләнгән бәгъзеләр, соңгы айларда инде Киевнең сөйләшергә теләмәвеннән зарлана башлады. Узган атнада да Кремльнең матбугат хезмәте: «Возможно ли выйти сейчас на мирное урегулирование с участием киевского режима и его нынешней позицией – ответ однозначный. Нет, невозможно. Никаких предпосылок для этого нет, об этом, в частности, говорил Путин», – дип уфтанды. Белүебезчә, Киев үзенең «тынычлык формуласы»н әле узган ел ноябрьдә «зур егермелек» саммитында ук бәян итте. Дөрес, аның беренче пунктында ук РФ гаскәрләрен басып алынган территорияләрдән чыгару таләбе куела. Нәкъ менә шуңа барып төртелә дә инде сөйләшүләрнең башланмау сәбәбе. Шул ук вакытта Согыд Гарәбстаны 5-6 август көннәрендә Җиддәдә Украинадагы коралды низагны җайга салу буенча очрашу үткәрергә җыена икән. Wall Street Journal язуынча, анда 30 илдән вәкилләр чакырылган, тик Россиягә чакыру килмәгән. В.Зеленскийның «тынычлык формуласы»н гамәлгә ашыру буенча анда дәүләт башлыклары киңәшчеләре дәрәҗәсендәге очрашу әзерләнүен Киев тә раслаган. Бу атнада инде Вашингтонда АКШ-Украина сөйләшүләре башланачагы да мәгълүм.

Bloomberg язуынча, Украина лидеры В.Зеленский сентябрьдә Нью-Йоркка БМО Генераль Ассамблеясенә барырга җыена икән. Мәгълүм ки, формула 10 пункттан тора (алар арасында Украина җиреннән РФ гаскәрләрен тулысынча чыгару, барлык хәрби әсирләрне һәм депортацияләнгән затларны да азат итү, азык-төлек вә энергетика иминлеген тәэмин итү кебекләре дә бар). В.Зеленскийның анда бер атна дәвамында булырга һәм БМО ГА ның башка утырышларында да катнашырга җыена. Мәскәүдә моны Киевнең чираттагы провокациясе дип кенә бәяләгәннәр.

Мәскәү шәһәр суды тарафыннан быел 17 апрельдә, Россиядә өнәлмәгән «Свободная Россия» дигән оешма белән хезмәттәшлектә һәм чит илдә чыгыш ясаганы өчен дәүләткә хыянәттә гаепләнеп (РФ ЖК, 275 нче маддә), катгый режимлы колониядә тоту шарты белән 25 елга хөкем ителгән һәм 700 мең сум штраф та салынган сәясәтче вә журналист В.Кара-Морза һәм аның адвокатларының, гаделлек эзләп, гомуми юрисдикцияле беренче апелляция судына биргән шикаятьләре канәгатьләндерелмәгән һәм хөкем карары үзгәрешсез калдырылган. Шул ук вакытта, 24-25 июнь көннәрендә фаҗигагә китергән коралды фетнә оештырганы өчен РФ президенты тарафыннан хыянәттә гаепләнгән ЧВК «Вагнер» җитәкчесе Е.Пригожин суд җаваплылыгыннан азат ителде.

1 нче биттә – Арча районының Ташкичү авылында узган фолькльор фестиваленнән бер күренеш. Фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

Хәрби кануннар кырыслана

Россиянең Административ хокук бозулар кодексында төзәтмәләр барлыкка киләчәк. Повестка алгач, сәбәпсез военкоматка килмәгән өчен җәза катгыйлана. Моның өчен штрафлар 50 меңгә кадәр артачак, хәзер исә 500 сумнан 3000 гә кадәр штраф каралган. Шулай ук, военкоматка гаилә хәле үзгәрү, белем алу, эш, уку урының, вазифаны яки яшәү урынын алмаштыру турында хәбәр итмәгән өчен дә 10-20 мең сум штраф кертү күздә тотыла. Бу хакта «Коммерсантъ» газетасы яза.

Дума бу үзгәрешләрне зур күпчелек белән кабул итте. Тавыш бирүдә катнашкан 369 депутатның 1 се каршы, 19 ы – битараф, 349 ы – яклап чыкты.

Шулай ук армиягә чакыру яше 30 яшькә кадәр артты. Башта чакыру 21-30 яшь булачак дип каралса, хәзер түбән яшь 18 килеш кала.

Дәүләт думасының Оборона буенча комитеты рәисе Андрей Картаполов әйтүенчә, үзгәрешләрнең төп сәбәбе – «бүгенге көндә шушы әйбернең кирәк булуы». Мобилизацион резерв сорала. Картаполов чит илгә китәргә теләүчеләр турында – «юлларына ак җәймә» дигән. Әмма ак җәймә һәркемгә дә түгел. Повестка бирелгән очракта, ул кешеләр чит илгә китә алмаячак. Элек повестка кешенең кулына тоттырылгач бирелгән дип санала иде. Хәзер электрон реестрга егетнең исеме кертелә икән, ул кеше инде чит илгә чыгып китә алмый – чит ил тыела. Эш урынына повестка килә, әмма кеше аны алмый икән – ул барыбер бирелгән санала.

«Армиягә барырга тиешле кешеләргә чит илгә чыгу тыелырга тиеш. Бу – гап-гади әйбер. Гражданнарның күпчелек өлеше – нормаль патриотлар. Әмма кабәхәтләр бар, алар нормаль кешеләргә караганда 2 тапкыр күбрәк», – дигән Дума депутаты Виктор Соболев.

Аның сүзләренчә, өлешчә мобилизация вакытында 300 мең кеше чакырылган, ә 600 мең кеше призывтан чит илгә качкан.

Бу закон проектын икенче укылышта Дәүләт Думасының дәүләт төзелеше һәм закон чыгару комитеты хуплады.

Закон буенча нинди штрафлар карала?

Бер сәбәпсезгә повесткада күрсәтелгән вакытка һәм урынга килмәгән өчен – 40-50 мең;

Гаилә хәле үзгәрү, белем алу, уку урыны, эш урыны яки вазифа, яшәү урынын (регистрация белән раслanмаган) алмаштыру турында, 6 айга кадәр илдән китү яки кире кайту турында хәбәр итмәгән өчен – 10-20 мең (хәзер болар өчен штраф юк);

Хәрби-транспорт мобилизация вазифаларын башкармаган өчен – физик затларга 15-25 мең, вазифаи затларга – 40-50 мең, юридик затларга – 350-400 мең;

Медицина тикшеренүеннән качып йөргән өчен – 15-25 мең;

Хәрби учет документларын аңлы рәвештә бозган яки югалткан өчен – 15-25 мең;

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылырга тиеш гражданнарга хәбәр итүне һәм аларның килүен вакытында оештырмаган өчен вазифаи затларга – 60-80 мең, юридик затларга – 400-500 мең;

Мобилизация планнары нигезендә җыелу пунктларына яки хәрби булекләргә техника алып килүне оештыру вазифаларын башкармаган өчен вазифаи затларга – 60-80 мең, юридик затларга – 400-500 мең.

Беренче мәртәбә хәрби учетка кертелергә тиешле гражданнар исемлеген хәрби комиссариатларга тапшырмаган өчен – 400 мең сум;

Гражданнарны хәрби комиссариат чакыру турында хәбәр итмәгән өчен (шул исәптән электрон формада хәбәр итмәгән өчен дә) вазифаи затларга – 40-50 мең сум һәм юридик затларга – 350-400 мең сум;

Хәрби учетка кертелергә тиешле кешеләр турында белешмә, аларның эшкә яки белем бирү оешмаларына алу, эштән яки укудан китүләре турында мәгълүмат бирмәгән өчен – 50 мең.

Закон 1 октябрьдән үз көченә керергә тиеш, диелә хәбәрдә.

intertat.tatar.

«Гашыйклар тавы» экранга чыгачак

«Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Татарстанның халык язучысы Илдар Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәре буенча фильм төшерергә җыена. 27 июльдә кастинг үтте. Анда 20-30 яшьлек егет-кызлар һәм 50, 60, 80 яшьлек өлкәннәр чакырылган иде. Барлык катнашучыларның татар телендә камил сөйләшүе шарт итеп куелды.

Илдар Юзеев «Гашыйклар тавы» әсәрен 1985-1986 нчы елларда яза. Аның сәхнә тарихы бик бай. Ә 2014 елда Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында шул исемдә спектакль кабат куела һәм ул әлегәчә тамашачыларның иң яраткан сәхнә әсәрләренең берсе булып кала.

«Бу юлы Илдар Юзеевның әсәренә тукталырга булдык. Кинофильм өчен сценарийны аның улы драматург Салават Юзеев язды, фильмны да ул төшерәчәк. Әлегә төгәл урынны әйтүе кыен, шулай да Әтнә районын, Лениногорскины күзаллап торабыз», – диде бу җәһәттән кастинг-директор Ирек Хафизов.

Актерларны Салават Юзеев белән бергә «Татаркино» учреждениесе директоры Миләүшә Айтуганова, Татарстанның атказанган артисты Ирек Хафизов сайлады.

29 августта Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Роберт Миңнуллинга багышланган «Яшәргә икән, яшәргә!» дип исемләнгән концерт узачак.

Роберт Мөгаллим улы «Яшь ленинчы», «Казан утлары», Татар телевидениесендә эшләп татар матбугаты, журналистика үсешенә, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, җәмәгать эшлеклесе буларак милли тормышыбызны көйләүгә өлеш кертте, шуның өстенә татар һәм башкорт телләрендә кырыклап китап иҗат итте. Балаларның үз шагыйренә әверелде. Авылда, шәһәрдә булсын Р.Миңнуллинның шигырьләрен ятлап үсмәгән бер генә бала да юктыр. Шулар белән бергә бик күп яраткан җырларыбызның авторы да әле ул. Аның «Алтын балык», «Гомерләр үтә икән ул», «Килен төшкәндә», «Кайда сез, яшьлек елларым?», «Соңдыр шул, соңдыр», «Талбишек», «Яратыгыз», «Әни кирәк», «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан», «Әрем исе, әре тәме» һ.б. җырларны җырлап ничә буын эстрада җырчылары алмашынды. Р.Миңнуллин җырлары бүген дә сәхнәдә яңгыраудан туктаганы юк, чөнки алар – туган җир, туып-үскән нигез, әти-әнине кадерләргә, мәхәббәтне сакларга чакыра торган йөрәктән чыккан җырлар. Концертта Салават Фәтхетдинов, Айдар Галимов, Венера Ганиева, Идрис Газиев, Римма Ибраһимова, Рәсим Низамов, Нәфкать Нигмәтуллин һ.б. чыгыш ясаячак.

Филармония абонементлары сатуда

1 августтан 15-енә кадәр Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә абонементлар ярминкәсе була. Абонемент бер билет белән ел әйләнәсенә бер тема яки музыка жанры белән берләштерелгән берничә концертны карап кайту мөмкинлеге бирә. Аерым-аерым билетлар сатып алуга караганда, абонеметтан файдалану җайлырак та, арзангарак да төшә. Быел филармония 20 абонетемент тәкъдим итә, бу исә 80 концерт дигән сүз.

Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры киләсе иҗат фасылында утыз еллыгын билгеләп үтә һәм концертларга Мәскәү, Санкт-Петербургтан дәрәҗәле кунакларны чакырырга җыена. Алар арасында Мәскәүдән Динә Гарипова һәм Түбән Новгородтан Венера Гыймадиева исемнәрен уку сөенечле булса да, татар кызларының туган-үскән җирләрендә эш таба алмыйча, читтәге театрларга сыенырга мәҗбүр булулары бер дә шатлыклы хәл түгел...

Иң күп абонементлар филармониянең әдәби-музыкаль лекториенә туры килә. Алар «Бөек исемнәр», «П.И.Чайковскийның 100 ария һәм романсы» һ.б. исемнәр белән берләштерелгән концертлардан тора. «Төрле гасырлар музыкасы», «Опера һәм спектакльләр» дигән өр-яңа концерт шәлкемнәре лекторийның һаман эзләнүдә булуын күрсәтә.

Гастрольгә Тыва республикасыннан «Алаш» тамак белән җырлау ансамбленең дә киләчәген белгәч Казан халкы билет алырга ябырылып килер әле, чөнки тамашачыбыз талантлы егетләрне яратып өлгерде. Мәскәүдән Н.Надеждина исемендәге дәүләт академия бию ансамбленең дә яңа иҗат фасылында чакырылган артистлар исемлегендә булуы программаның ни дәрәҗәдә җитди икәнен күрсәтә.

Филармония абонементларын барыннан да бигрәк балалар ярата. Алар өчен нинди генә концерт-тамашалар юк! «Домисольканың Музыка илендә маҗаралары», «Тылсымлы балачак дөньясы», «Джаз дөньясына сәяхәт» һ.б.

Филармония кассасына 10.00 дән 19.00 гә кадәр килергә иренеп, абонементларны www.tatfil.ru сайтыннан алырга күнегүчеләр ташлама булсын өчен «Ярмарка» промокодын кулланырга онытмасын. 15 августтан исә аерым-аерым концертларга билетлар сата башлаячаклар.

«Ибн Фадлан»ны бушлай карап була

«Хозур» нәшрият йорты «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмын YouTubeка чыгарды. Димәк, хәзер кинофильмны барлык теләүчеләр интернет челтәрендә бушлай карый алачак.

«Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы – «Россия – ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме заказы буенча Ислам мәдәнияте, фәнне һәм мәгарифе фонды ярдәме белән Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төшерелгән иде. Фильм Багдад илчелеге белән Идел буе Болгар дәүләтенә килгән гарәп дипломаты Әхмәд ибн Фадланның юл язмаларына нигезләнгән. Илчелекнең килүе Идел Болгарстанында 922 нче елда ислам дине рәсми дин буларак кабул ителү белән бәйле.

Быелтыр Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә беренче тапкыр күрсәтелгән бу фильм тамашачыда зур кызыксыну уяткач, фестивальне оештыручылар аны дүрт тапкыр кабатлап күрсәтергә мәҗбүр булды. Шуннан соң быелның март аеда ул киң прокатка чыккан иде.

Театрларыбыз өчен тавыш бир!

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия һәм Әлмәт Татар дәүләт драма театрлары «Иң шәп милли театр» төрендә «Звезда Театрала» премиясенә тәкъдим ителгән. Быел ярышта Татарстан, Бурятия, Карелия, Адыгея, Якутия, Удмуртия, Мари Эль, Осетия коллективлары катнаша. Бәйгегә 24 меңнән артык гариза килгән. Үткән ел белән чагыштырганда бу сан ике тапкырга артык. Җиңүчене бәйгенең сайтында тавыш биреп, тамашачы үзе сайлаячак. Хәзерге вакытта ун иң шәп театр арасында сайлау бара һәм ул сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Шуннан соң һәр номинация буенча иң күп тавыш җыйган өчәр катнашучыны бәйгенең шорт-битенә теркиячәкләр һәм аңа кадәр җыелган тавышлар юкка чыгып, тавыш бирү яңадан башланачак. Йомгаклау өлеше ноябрь ахырына кадәр дәвам итә. Җиңүче 4 декабрьдә Вахтангов театрында узачак тантанада игълан итеп, тамашачы бүләген тапшырачаклар.

Театрлар өчен түбәндәге ссылка буенча тавыш бирергә мөмкин http://www.teatral-online.ru/star/longlist/

- Ананаста итне эшкәртә торган энзимнар бар, шунлыктан ул, ашаганда, авызны яндыра. Бу җимеш бромелайн ферментының табигатьтә безгә мәгълүм бердәнбер чыганагы булып тора. Бромелайн чыннан да аксымны эшкәртә, шунлыктан ананас ашаганда авыз, тел һәм иреннәр яна. Әмма ашказаны кислоталары әлеге ферментны тарката, шунлыктан куркырга кирәкми.
- 1967 елда биг-мак уйлап тапкан һәм аны гомере буе яратып ашаган Джим Деллигатти 2016 елда 98 яшендә генә дөнья куйган.
- Рубик шакмагының барлыгы 43 квинтиллионлап комбинациясе исәпләнсә дә, аларның күпчелеген уртача 20 йөреш ясап чишеп була.

Күркәм эшләр мирасханәсе

Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать дәүләт музее быел 55 еллыгын, аның директоры Розалия Миргалим кызы Нургалиева 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Бу форсатта музей һәм аның җитәкчесе Р.Нургалиева хакында җылы сүз ирештерү урынлы.

Р.Нургалиева 1953 елның 7 августында Казан шәһәрендә дөньяга килә. 1976 елда Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлый. 1979-1990 елларда архитектор, РСФСР Сәнгать фонды иҗат-производство комбинатында баш рәссам вазыйфасын башкара, 1990-1992 елларда идарә башлыгы урынбасары – баш рәссам, 1992-2005 елларда Казан шәһәре хакимиятендә архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары, шәһәрнең баш рәссамы, шәһәр дизайнны идарәсе башлыгы. 2006 елның сентябреннән хәзергә кадәр Татарстан республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музее директоры. Татарстанның Атказанган архитекторы, атказанган мәдәният хезмәткәре, 2013 елдан Россия Сәнгать Академиясенең мактаулы әгъзасы...

Җитәкченең күп гомере, башкарган эшләре Сынлы сәнгать музеена бәйле. Шуларның берсенә генә тукталыйк.

2017 елның июль аенда Айдар Урманчы атасы Бакый Урманченың шәхси архивын Сынлы сәнгать музеена тапшыра. Элекке хезмәттәшем, танылган каллиграф Нәҗип Нәккаш без фәкыйрегезгә Бакый Урманче архивын тасвирларга кеше эзләүләре хакында җиткерде. Бөек рәссам исеме белән дә кызыксыну көчле иде, музей директоры Р.Нургалиева белән очрашуга киттек. Ул «киләсеңме, килмисеңме», дип сорамыйча гына: «Эшкә алабыз», – дип, үз сүзен кыска һәм төгәл җиткерде. Эшли башлагач та, Розалия Миргалим кызының шундый ук төгәллек һәм кыскалык белән эшли белүе аның эш стиле булуы аңлашылды.

Эшкә килгән вакыт музейда татар халкының бөек рәссамы, сынлы сәнгатькә нигез салучыларның берсе Бакый Урманченың 120 еллык юбилеена әзерлек дәверенә туры килде. Шул елда Б.Урманчега багышлап 5 халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Аларда Урманченең шәхси архивына кыска гына күзәтү рәвешендә чыгыш та ясарга туры килде.

Розалия Миргалим кызы Б.Урманче иҗатын танытуда күп көч куйды. Рәссам-скульпторның күргәзмәсе «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә даими эшләве шуңа ачык мисал. Икенчедән, ул шәхси архив белән танышканда Урманче шигырьләренең үзенчәлекләякларына игътибар итте, аларны матбугатта бастыру кирәклегенә басым ясады. Аның идеясе һәм тырышлыгы белән Урманченың шигырьләре 2022 елда рәссамның 125 еллык юбилее уңаеннан Татарстан китап нәшриятында (мөхәррире В. Камалиева) нәшер дә ителде. Җитәкче архитектор-дизайнер булуына карамастан, дөнья әдәбиятыннан яхшы хәбәрдар булуы сәбәпле, бу проект уңышлы чыкты, Урманченең шигъри мирасы укучылар кулына ирешә. Р.Нургалиева Шәрык шигъриятына гашыйк. Аның Урманче шигырьләрендә шәрык шигъриятенә хас алымнарга игътибар итүе, аның шәхси архивын эшкәртү һәм мирасын киң катлау укучыга ирештерү кирәклеген дә сиздерде. Нәтиҗәдә,«Җыен» фондында рәссам-скульпторның шәхесен һәм киң кырлы иҗатын укучыга таныту йөзеннән җыентык бастырылды.

Сынлы сәнгать музеенда оештырылган һәр күргәзмәдә Р.Нургалиева – төп әйдәп баручыларның берсе. Монда аның дизайнерлык һөнәре һәрвакыт ярдәмгә килә. Шуңа күрә һәр күргәзмә сәнгати югарылыкта уздырыла. Мәсәлән, 2019-2023 елларда гына зур күргәзмәләрдән Х.Якуповның 100 еллыгы, Н.Фешинның 140 еллыгы уңаеннан оештырылган күргәзмәләрен, XIX гасырның ахыры-XX гасыр башы сынлы сәнгатен, археологик байлыклар һәм башка кыйммәтле чыганакларны туплаган Лихачевлар коллекциясен тамашачыга күрсәтүдә зур тырышлык куйды. 2022 елның җәй-көз айларында Идел буе Болгарында ислам динен кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Россия күләмендә танылган каллиграфистларның сәнгать әсәрләреннән торган «Шәмаил-арт» күргәзмәсен тамашачы яратып кабул итте. Бу күргәзмәгә Башкортстан рәссамы Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Ринат Миңнебаев картиналарының күргәзмәсе кушылып китү дә татар халкының борынгы тарихын хәзерге тамашачыга күрсәтүдә бер омтылыш булды. «Шәмаил-арт»ны искә алганбыз икән, Татарстан Мәдәният министрлыгы хуплавы һәм матди ярдәме белән Риза хәзрәт Фәхретдин тарафыннан тәүге мәртәбә татар теленә тәрҗемә ителгән «Ибне Фазланның Болгарга килүе» хезмәте Сынлы сәнгать музее җитәкчесе тәкъдиме белән нәшер ителде. Р.Фәхретдин кулъязмасының күчермәсе Б.Урманченың шәхси архивында саклана. Материал шуннан алынды. Урманче бу язманы XX гасырның 60 елларында «Казан утлары» журналында бастырырга теләгән, әмма вакытында дөнья күрми калган. Аннары, Розалия Миргалим кызының халыкара проектлар белән эшләвен дә искә алмый булмас. 2020–2023 елларда Сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясе һәм «Хәзерге заман сәнгать галерея»сендә Төркиянең танылган рәссамнары Левент Карадуманның шәмаилләре, Ялчын Гёкчебаг һәм Рәшит Алтуннарның сәнгать әсәрләре Татарстан халкына күрсәтелде. Туниста яшәп иҗат иткән рус рәссамы А.Рубцовның шундагы милләтләрнең тормышын сурәтләгән картиналарыннан торган зур күргәзмәсе 2021 елның 7 декабреннән 2022 елның июнь башына кадәр эшләде. Бу күргәзмә дә Татарстан халкында кызыксыну уятты. А.Рубцовның иҗат мирасы Тунис һәм кайбер Европа дәүләтләрендә саклана. Бу мирасны туган иленә кайтару, Казанда оештыру җиңел булмагандыр. Р.Нургалиеваның шул авырлыкларны җиңеп дөнья күләм рәссамның иҗат мирасын Татарстанда күрсәтә алуы һәръяктан мактауга лаек. Җитәкченең халыкара проектлары болар белән генә тәмамланмый, әлбәттә. Испан халкының бөек шәхесе – режиссёр, рәссамы Сальвадор Далиның график әсәрләреннән торган күргәзмәсе «Хәзерге заман сәнгать галерея»сен бизәп кенә калмады, рәссамның тирән фәлсәфи әсәрләре белән таныштыру мөмкинлеген дә тудырды. 2021 елда Татарстанда Якутиянең әдәбият һәм сәнгате көннәре узганда «Хәзинә»дә якут рәссамнарының сәнгать әсәрләре күргәзмәсе дә эшләде. Аларның югары дәрәҗәдә камил эшләнгән милли сәнгать әсәрләре беркемне дә битараф калдырмагандыр. Сынлы сәнгать музеенда уздырылган күргәзмәләрнең болар берничәсе генә. Бу урында шуны да өстик: Р.Нургалиева җитәкчелегендә Татарстан сынлы сәнгать дәүләт музее Россиянең башка регионнары, мәсәлән, Мәскәү, Санкт-Петербург, Саратов, Ульяновск, Уфа кебек шәһәрләрдә яшәп иҗат итүче рәссам һәм сынчыларның сәнгать әсәрләре белән дә Татарстан тамашачысын таныштыру мөмкинчелеген булдыра. Соңгы вакытларда Мәскәүнең Третьяков дәүләт галереясендә Сынлы сәнгать музее фондында сакланган картиналар күргәзмәсе оештырылып, Татарстан сынлы сәнгатен ил күләмендә танытты.

Сынлы сәнгать музее татар милли сынлы сәнгатен халыкка танытуда да мөһим роль уйный. Соңгы берничә елда гына да биредә татар халкының милли тарихын чагылдырган Р.Заһидуллин күргәзмәсе эшләде. XX гасырның 80–90 елларында татар сынлы сәнгатендә әйдәп барган рәссамнардан Г.Рәхманкулова, И.Зарипов, Р.Вахитов, Р.Килдебәкев, Р.Гыйләҗев, З.Гимаев, Х.Латыйпов, Р.Сәлахов, Ш.Шәйдуллиннарның күргәзмәләрен Казан кунакларына танытуда да әһәмияте биниһая зур булды. 2022 елда Хәзерге заман сәнгать галереясендә «Шәмаил-арт» күргәзмәсе татар каллиграфия сәнгатенең тарихын, аның бүгенгесен һәм киләчәген киң катлау тамашачыга таныштырды. Татар шәмаилләрен халыкка танытудагы әлеге хезмәт беренче генә түгел. 2023 елда гына «Хәзинә» сәнгать галереясендә музей фондында сакланган шәмаилләр һәм 2023 елның апреленнән бирле Н.Нәккашның шәмаилләр күргәзмәсе эшләп тора.

Розалия Миргалим кызы Сынлы сәнгать музееның традицияләренә тугрылык саклаган хәлдә, аның эшчәнлегенә заман төсмерләре дә бирә. Интерактив методлар, мәгълүматларның электрон вариантлары һ.б. алымнар да файдаланыла. Музейда җитәкчелекнең хуплавы белән бер ел эчендә 80-120 ләп проект тормышка ашырыла.

Музей фондында рус, татар һ.б. халыкларның меңәрләгән картина, скульптура, татар шәмаилләре, христиан диненең бай мирасы саклана. Алар һәр даим карап, төзәтеп торуны таләп итә. Музейда белемле рәссам-реставраторлар да хезмәт куя. Р.Нургалиева киләчәктә реставрация үзәген булдыру теләге белән дә яши. Бу – музей фондында сакланган тарихи әһәмиятен югалтмаган кыйммәтле ядкәрләрне кабат тамашачы хөкеменә тапшырырга мөмкинлек бирә.

Музейда балалар белән эшләүче төркемнәр дә бар. Алар яшь балаларны рәсем сәнгатен аңларга, эшләргә өйрәтә. Гомумән, Сынлы сәнгать музее тулы канлы тормыш белән эшли. Җитәкченең бүген дә иҗат потенциалы ташып тора, зур проектларны тормышка ашыру уе белән яши.

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН.

Халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе

(Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мактаулы академигы Равил Фәйзуллинга 80 яшь)

Равил Габдрахман улы Фәйзуллин – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык шагыйре (1999), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мактаулы академигы (2007).

Р.Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа. Котлы Бөкәш урта мәктәбеннән соң (1960) Казан дәүләт университетын тәмамлый (1965). 1965-1967 елларда армия хезмәтендә була. 1968-1972 елларда – Татарстан Язучыларының Әлмәт оешмасы җитәкчесе. 1973-1977 елларда – Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары. Шул ук елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантура тәмамлый. 1989 елдан – «Казан утлары» журналының баш мөхәррире. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, шагыйрь иҗатының иң күп өлеше татар халкының бу төп әдәби-нәфис басмасы белән бәйле. Студент елларында ук ул төрле бүлекләрдә әдәби хезмәткәр булып эшли. Күп еллар үткәч, журналның баш мөхәррире булган дәвердә, журнал тарихында чыккан мең санның өч йөзләбе (!) Р.Фәйзуллин имзасы белән дөнья күргән.

Р.Фәйзуллин – студент елларында ук Казанда ике шигъри китап чыгаруга ирешә. 22 яшьтә Язучылар берлегенә кабул ителә һәм СССРда Язучылар берлегенең иң яшь әгъзасы була. Ул – 60 нчы елларда әдәбиятка шаулап килгән яшьләрнең берсе. Кыю иҗаты, гражданлык активлыгы, популярлыгы, таланты һәм хезмәт сөючәнлеге аны шул чор шагыйрьләренең лидеры дәрәҗәсенә күтәрә. 1960 елда яшь шагыйрьләрнең Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК оештырган Бөтенсоюз фестивалендә җиңүче була.

● **Равил Фәйзуллинның фикердәш дуслары: Зиннур Мансуров, Илсөяр Иксанова, Газинур Моратов.**

Аның беренче шигырьләре («Нюанслар иле» циклы (1964), «Рәсем ясыйм» (1965), «Аҗаган» (1966), «Монологлар һәм диалоглар» (1967), «Кыска шигырьләр» (1978) һ.б. җыентыклары) новаторлыгы, безнең шигърият өчен бик үк традицион булмаган ирекле, мәгънәви яктан тирән эчтәлекле булулары белән тиз арада укучыларның һәм тәнкыйтьчеләрнең игътибарын җәлеп итә.

Р.Фәйзуллин – шигырьдә кыскалыкка, аз сүзлелеккә омтылучы шагыйрь. Нечкә тоем, тирән уй, фәлсәфи фикер, гражданлык пафосы – шагыйрь иҗатының төп асылы.

70 нче еллардан башлап ут халык иҗатына нигезләнгән поэтик формаларны үзләштерүгә игътибарын көчәйтә. Сурәтләүдәге, образлы фикерләүдәге индивидуаль үзенчәлеген саклаган хәлдә, халыкчанлык юнәлешендә дә яңа биеклекләргә ирешә («Мәрмәр» (1969), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1979), «Кошлар юлы» (1981) һ.б. китаплары).

Р.Фәйзуллин поэма жанрында да («Гадиләргә гимн» (1971), «Көрәшчеләр» (1975), «Сәйдәш» (1981) һ.б.) һәм балалар поэзиясе өлкәсендә дә («Күмәч пешерүчеләр җыры» (1977), «Газиз китабы» (2005) һ.б.) актив иҗат итә. Ул шулай ук күп кенә популяр җырлар авторы да. Шагыйрь әдәбият, сәнгать, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә, сәясәткә багышланган әдәби-публицистик мәкаләләр, чит илләргә иҗади командировкалары, сәяхәтләре турындагы юлъязмалар авторы буларак та яхшы билгеле («Җырларда – ил гаме» (1984), «Илбагар уйлар» (2011) һ.б.).

Аның шигырьләре, поэмалары һәм публицистикасы Европа һәм Азия халыклары телләренә тәрҗемә ителгән. Р.Фәйзуллин иҗаты Италия, Англия, Франция, Сүрия, Венгрия, Монголия һ.б. илләрдә билгеле. Аның исеме һәм иҗаты күптомлы рус антологияләренә, дәреслекләргә, энциклопедияләргә кертелгән. Әсәрләренең кайбер үрнәкләре «Бөтендөнья әдәбиятлары китапханәсе» сериясендә чыккан томлыкларның берсендә урын алган.

Р.Фәйзуллин – Республика комсомолының М.Җәлил исемендәге (1970), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт (1978), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге (2012) әдәби премияләр лауреаты. 1985 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек була. Ул шулай ук Дуслык ордены (2006), төрле медальләр, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең күпсанлы Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 1990-1995 елларда – Татарстан Югары Советы депутаты.

Соңламый торган хат

Минем архивымда, икенче ел инде, адресатларына барып җитмичә, бер хат яткан икән. Көнендә укылган да, вакыты җиткәч, кирәге чыгар бәлки, дип бер читтәрәк куелган да, яткан да, яткан. Күрәсең, ул минем сиксәнемне көткән. Инде сиксәнем дә үтеп киткән икән. Хәзер миннән ярты яшькә кечерәк булган Равил Фәйзуллин «энекәшкә»дә сиксән тулып килә. Аллаһы Тәгаләдән бик гадел рәвештә шулай насыйп иткәндер, бәлки. Мин бу хатны сиксәнем үткәннән соң, кичегеп булса да, укучылар игътибарына җиткермәкче итәм. Чөнки сурәтләнгән вакыйга минем белән генә чикләнми. Калганы барысы да аңлашылыр сыман.

«Мөхтәрәм Айдар әфәнде! Гаҗәеп гомер бәйрәмегез котлы булсын!

Мин, Филисә Хәкимова, моннан 55 ел элек булган бер кадерле хәтирәне яңартмакчы булам.

...Сурәтләргә сүзләр җитмәс кышкы хозурлык. Атна буе ишелеп-ишелеп яуган кар, күз ачкысыз җил-буран, болай да иңкүлектәрәк утырган авылыбызны чын ак кар патшалыгы итте.

Ник олы юлда бер трактор, йә чана тарткан җәяүле күренсен! Кар көрәвебез дә күңел өчен генә. Су юларыбыз да ачканчы ук карга күмелә бара. Койма-капка өсләреннән йөреп кинәнәбез. Морҗа төтеннәрен барлап-күзләп торабыз. Электр чыбыклары да өзелгән, ут та юк.

...Беләм, Сезгә боларны сурәтләп торасы юк. Чөнки сез үзегез табигатьнең дә, кешелекнең дә, җир-күкләр һәм дә күңелләрнең дә кичереш-халәтләрен бар нечкәлеге белән тойган, тасвирлаган әдип.

Хикмәт шунда ки, әле буран тынаргада өлгермәде, кичкырын авыл советында кизүдә торучы апабыз шундый хәбәр китерә:

– Иртәгә Казаннан ике яшь шагыйрь киләчәк, ди. Белдерү язып эләргә куштылар. Равил Фәйзуллин, Айдар Хәлим, диделәр. Әйдә, син үзең беләсеңдер инде...

Шигырь белән шыплап тулган күңелдә дә уй бураны купты.

– Китапханәгә барып килергә. Бу кышкы салкында башларына нинди эш төшкән, диген. Киемнәре дә өлтерәгән генәдер, киез итекләре дә юктыр...

– Әгерҗедән Көчеккә чаклы кырык чакрым. Трактор чанасында килерләрдер. Толып хәстәрләгән булсалар ярый инде...

– Афишаны җил ертачак. Урамга чыккан кеше юк. Кем укысын?! Кеше җыелмаса...

– Хәер, иртән колхоз радиосыннан белдерү тапшырырга була. Бар халык иртәнге алты тулганчы ук радионы ачып куя бит...

Озын сүзнең кыскасы: Ходайның нинди хикмәте булгандыр, билгеләнгән сәгатькә зал шыгрым тулы иде. Әле кичәнең башлануын шактый гына көтеп утырырга туры килде. Ник бер кеше урыныннан кузгалсын!

...Сәхнәнең ике ягында байлардан калган ике алтмышлы лампа яна. Алар һәр ике шагыйрьне ялкын телләре белән үзенчә сәламләп каршылый, алкышлап куя. Равил Фәйзуллин белән Айдар Хәлим атлы ике яшь шагыйрь алмаш-тилмәш, сәгатьләр буе шигырь укый. Ә зал... Ә авылымның шигъри җанлы кешеләре, дөньяларын онытып шигырь тыңлый. Дөньялар да кар аклыгына гына түгел, шигъри ямьгә, шигъри гамьгә төренә...

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең «Бәхилләшү» романы минем җаныма якын шундый сүзләр белән тәмамлана: «Ул эскәртләрне, ул ризыкларны, кырау төшкән бәрәңге сабагы, баллы салам исләрен сагынып яшәвемне гаеп итмәгез инде...»

Минем дә бу хатирәмне Мөхәммәт абыйга охшатыбрак тәмамлыйсым килә: «Минем узган гасырларны, авылымның еракта калган ак кышын, шигъри җанлы авылдашларымны һәм хөрмәтле шагыйрем, Сезне сагынып яшәвемне гаеп итмәгез инде...» Күренекле, мәшһүр шәхесләребез Айдар һәм Равил агалар алдында тирән ихтирам белән башымны иеп һәм игелекле гомерләр теләп, Филисә Хәкимова. Казан, 2022 ел, 14 декабрь».

Айдар ХӘЛИМ.



Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Төрле еллардан...

ҖИЛ – ВАКЫТ УЛ...

Җилләр шатлык алып киләләр.
Җилләр картлык алып киләләр.
Җилләр диннәр алып киләләр.
Җилләр чирләр алып киләләр...
Җилләр алар шундый: теләсәләр –
әллә ниләр алып киләләр!
Җил – Вакыт ул, белми тынычлык!
Җил тамырын кисәр кылыч юк!

* * *

Ни бар канда, ни бар җанда
ачтым салдым. Ышандым.
Сөенечләрдән-көенечләрдән,
ичмасам, бер бушаныйм!
Ә чынлыкта авырайдым,
Уй-исәп барыбер басты:
Ни колакка ирешәсен
төгәл белми, сер ачтым...

* * *

А. Хәлимгә

«Бу юлларны сагыныргбыз әле!
Тик кайтылмас бүтән менә...»
Әйе, сагынырбыз. Вакыт – Алла.
Ә без бары кеше генә...
Ә шулай да без – без булырбыз гел!
Дәрте калыр, дәрман бетсә дә!
Изүләрне чишеп юл чыгарбыз,
Иллдә зарыгып безне көтсәләр...

* * *

Эшең юк, язган чакта мин
үксимме, әллә көләм.
Ничек язганымны бары
бер үзем генә беләм!
Япа-ялгыз мин. Бу ялгыз чак –
иң бөек хөрриятем.
Вөҗданым белән сөйләшәм, –
шул минем шигърияте́м.

* * *

Курыкма, биек оч, Кошым!
Күк чикне беләмени!
Көл, күңел! Дөнья моңы
бер безгә генәмени!
Оч, оч, Кошкай, кис җилләрне!
Шаш, Рухым, – дуласын җан!
...Егылсак – белгән-күргәннәр
яхшыга юрасыннар.

* * *

Бәхетлеләр – ачык, киң күңелле,
риясыз, саксыз, ваемсыз.
Ә бәхетсез күп чак көчле көнче
һәм юкка да үче аяусыз...
Бәхетлеләр оныта, кичерәләр,
хөсетлелек нигә аларга?
Барсын күреп торган, һәрчак аек
бәхетсездән саклан дөньяда!

* * *

Гомерләре җыр булалган
Кешеләр – иң бәхетлеләр!
Язсам гына яшәвемне раслыйм.
Юньле эшем – йөзем аклыгы.
Язсам гына – Җирнең улы булам,
сөелүгә-назга хаклымын.
Язсам гына – бәхтем тулы, бөтен.
Язу эше – намус, кан эше.
Язсам гына – илгә, кешеләргә
файда итсәм генә мин кеше.

* * *

Н. Исәнбәткә

Яу-дауларны күргәннәр күп,
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп,
Вакыт-яу – иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

* * *

Кыз сынын ясады бер оста,
Ә кыз эчтән көлде, масайды.
«Җан өрсәң дә, оста, син ташка,
таш таш инде, тере мин – башка!»
...Акты гомер. Оста күптән юк...
Ә таш сын шул – көләч, яшь һаман!
Бөкре карчык килгән янына:
яшьлегенә – сынга яшь тама...

* * *

Яхшылыкның, диләр, әҗере күп.
Ә шулай да –
кайгылыга кушылып елый алмыйм.
«Бу да җәлли», – диеп рәнҗер күк.
Юк, үземне куймыйм яхшыга...
Ә шулай да...
бәхетлегә тыныч карый алмыйм –
сөенечтән, ахры, яшь чыга.

* * *

Синең өчен җан атмасам,
саргаймас, көймәс идем.
Бүтәннәрдә булса күңлем,
«бәгырем!» димәс идем.
Чарам булса, горур йөрткән
башымны имәс идем.
...Бергә булсак, сине, бәлки,
бу кадәр сөймәс идем.

* * *

Могҗизага яшьрәк чакта ышан,
гөл асылын җәен өз икән.
Язгы эзләр белән килгән идем, –
сезнең урамда да көз икән...
Бер вакыты җиткәч кай җирдә дә
пәрәвез җепләрен җил өзә.
Әй авыр, кайтмаска киткәнгә –
«Озак йөрмә, тиз кайт!» – дип кул изәү...

НӘСИХӘТ

Бушка алма берни бу дөньяда.
Җиңел килгән рәхәтлектән саклан.
Язмыш дигәннәре костырыр бер, –
ә косканың булыр чат кан!

Юләр булсаң гына шатлан –
җиңел килде, диеп, бу мал,
бу мәхәббәт, бу дан...
Җиңел үлереңә генә шатлан.

НИ МӘГЪНӘ?

Ни мәгънә шәп киемнән –
аны кем дә күрмәсә?
Ни мәгънә сау тәнеңнән –
кем дә кадерен белмәсә?
Ни мәгънә тау менүдән –
кем дә сәламләмәсә?
Ни мәгънә эч сереңнән –
аны кем дә белмәсә?

ТУГАННАРГА

Бергә чакта үскән идек
тал тамырлары кебек!

Безне бергә кайчак кайгы гына
җыя хәзер Туган нигезгә...
Без төрлебез төрле тарафларда
мәшәкатьле Тормыш-диңгездә.
Шатлыкларның, хәтта бәйрәмнәрнең
көче җитми очраштырырга.
...Ә бит беркөн беребез ким булып,
туры килер басып торырга!..

* * *

Усал дисәләр дисеннәр,
тик мескен димәсеннәр!
Үземә тисә тисеннәр,
ярыма тимәсеннәр!
Башымны төйсә төйсеннәр,
ярама тимәсеннәр!
Даныма тисә тисеннәр,
балама тимәсеннәр!

* * *

Гомер бакый Яхшы белән Яман
якалашкан, канда буталган...
Тарих – сәер: хәтерендә рәттән –
изге җан да, зина кылган да.
Алып бабай өйгән курганнар да,
Геростраг яккан храм да,
Клеопатра хатын патшаның
күкрәген чаккан елан да.

* * *

Кеше гомеренә караганда –
суга ятып тибрәнүче
күләгәләр күпкә ныграк!
Иртән төшкән чык сәгате озынрак!
Чишмәләрнең моңы мулрак!
Бу күкләр астында
мәңгелек иң ныгы –
Кешеләр хәтерен сеңдергән туфрак...

ЯЛГАН

I

Һәр әйтелгән ялган сүздән
мөгез чыкса маңгайга!
Кыяк үләннән күбрәк
мөгез булыр дөньяда!
Әле дә чыкмый. Юкса бездән
сабыйлар качар иде...
Олылар бер-берсен күреп,
акылдан шашар иде!

II

Һәр ялганнан җан көчләнә.
Күз нуры тоныклана.
Ялганчының, бер көн килеп,
баскан туфрагы яна!
Ә туфракка нәрсә ялган –
Табигать ул яңара!
Һәр ялганнан иң әүвәле
Ил аңы томалана...

ТУГАН ӨЙДӘ КҮРГӘН ТӨШ

Шундый матур төш!
Бөтен җир гел –
чәчәк тә гөл!
Чишмә дә инеш!
Һәм шунда...
мин имеш!
...Айны урак итеп гөл кистем.
Чүмеч йолдыз белән су эчтем!

ТУКТАРМЫ?

Җил – исүеннән туктармы,
җилкән корганга карап?
Чирәм – үсүдән туктармы,
очын кырганга карап?
Су – хәрәкәттән туктармы,
буып куйганга карап?
Адәм – көрәштән туктармы,
иреген тыйганга карап?..

ТАУ – ШУЛ УК ҖИР...

Тау – шул ук җир. Тик аңарга
башны чөеп карар җир.
Тау – шул ук җир. Туарга да,
күмелергә дә ярар җир.
Тау – шул ук җир. Тик һәркемнең
табанына ятмас җир.
Тау – шул ук җир. Биеклекне
бер югалтсаң, тапмас җир.

* * *

Шигырьнең кирәклеге турында
кайчак кирәкмәгән бәхәсләр дә
булгалый.

«Шигырьне укымыйлар...» дип
«сөенү» җиңелрәк.
Бездә әдәбият әнкәсе
гомердән Шигърият!
Әнкәләрне санламаучы
сантыйлар да җитәрлек.
Бездә шигырь – аңлаганга –
башың Себер китәрлек!

ШАГЫЙРЬ БУЛСАҢ...

Нечкә җанлы, чын иманлы
булып тууың кирәк.
Шатлык-кайгыңны аңларлык
җирлек булуы кирәк.
Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны күп халыклар
күмәк тануы кирәк.

РЕДАКЦИЯДӘН. Бүген Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Равил Фәйзуллинга 80 яшь тулды. Без каләмдәшебезне олы гомер бәйрәме белән ихластан котлыйбыз, аңа тазалык-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

Милләтебезнең рухи күтәрелеш чорында бу хәрәкәткә үз өлешләрен керткән шәхесләребез байтак. Дини, иҗтимагый-сәяси һәм тарихи хезмәтләре белән башка төрки халыклар арасында да дан казанган Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар тәрбиясендә үскән бер буын исә татар әдәбияты үсешенең яңа бер тармагын - заманча роман, повесть, хикәяләр иҗат итү тармагын башлап җибәргән. Әдәбият гыйлемендә «чәчмә әсәрләр яки проза, драма әсәрләре» дип билгеләнгән бу өлкәдә иң беренче уңышка ирешкән авторларыбыз арасында иң күренеклеләрдән Пенза төбәге кешеләре Муса Акъегетзадә белән Заһир Бигиев санала. Аларның «Хисаметдин мелла» белән «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романнары бер-бер артлы 1886, 1887 елларда Казанда дөнья күргән. Татарлар арасында заманча беренче проза әсәрләре туува рус һәм төрек әдәбиятлары үсеше дә үрнәк булган, этәргеч биргән, дигән фикерләр безнең әдәбият тарихын барлаучылар тарафыннан әйтелгәләде инде.

ешбез. Аның тәүге иҗат чоры әсәрләреннән кайберләренең дә яңа гасыр башында Оренбург шәһәрендәге «Кәримовлар басмаханәсе»ндә дөнья күрүен әйтеп киттек. Киләчәктә дә аның кайбер әсәрләренең шул шәһәрдән чыккан, укытучылар әзерләүче уку йортында бергә укыган дусты Габдерахман Дәүләтшиннең матди ярдәмендә нәшер ителәчәген дә истә тотсак – аның иҗат юлының өлешчә генә булса да шушы шәһәргә бәйле дип әйтергә хаклыбыз. Мәсәлән, авторы сөргендә чакта шактый гына.) Бертуган Рәмиевләр белән Уфада, мөфтияттә эшләгән еллардан ук дустанә мөнәсәбәттә булганлыгы турында хәзрәтнең үз истәлекләре сакланган. Моңа ул шәхесләрнең нәселе бер төбәктән - элекке Бөгелмә өязеннән икәнлеге дә, Рәмиевләрнең кайбер буын бабаларының дин әһелләре булуы да ярдәм иткәндер. Риза хәзрәтнең яшьтәше Дәрдемәнднең бабалары да бит чыгышлары белән хәзерге Әлмәт районына кергән Тайсуган авылыннан. Ш.Мәрҗани хезмәтләрендә бу

Дәрдемәнд даирәсендәге

Шул фикерне дәлилләрдәй бер мисал буларак, Дәрдемәнд һәм аның агасы Шакир Рәмиев хатларыннан берничә җөмлә китерү дә җитәдер, мөгаен. Мәгълүм ки, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд 1880-1881 елларда Төркиядә яшәгән. Ике бертуган еш кына хат алышканнар. Менә Шакирның 1881 елда энесенә язган хатларыннан кайбер җөмләләр. «Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә игътибар итми. Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китапларны, романнарны күбрәк алып кайта күр», дип язган ул энесенә.

● Дәрдемәнднең яшь чагы.

● Оренбург каласындагы «Хөсәения» мәдрәсәсенең төп укыту бинасы. З.Бәширов фотосы. Оренбург Дәүләт музее фондыннан.

Шул чор зыялылары арасында ул елларда: «Татарлар арасында хәзер чалмалы муллалар җитәрлек, чалмасыз муллаларга кытлык», дигәнрәк әйтем дә йөри, дип яза Ф.Кәрими бер китабында. «Чалмасыз муллалар»- киң белемле затларның халыкка заманчарак хезмәт итәчәге турында да , халыкның рухи үсеше өчен дини, гыйльми китаплардан тыш әдәби әчтәлекле хезмәтләрнең дә кирәклеге турында да шулай хәбәрләшкән ул чорның зыялы шәхесләре. Муса Акъегетзадә һәм аның чордашлары тудырган әдәби әсәрләрне укып үскән икенче, өченче буын вәкилләре исә шушындый фикерләрне тирәнәйткән, баеткан әсәрләр тудырырга хыялланган.

Шушы ук дәвердә Оренбург шәһәрендә дә әдәби-мәдәни җанланыш, күтәрелеш күзгә чалына. 1870 елларда монда милли мәктәп-мәдрәсәләр өчен рус теле укытучыларын әзерләүче Учительская школа ачыла. 1889 елдан заманча (җәдидчә) укытуга йөз тоткан « Хөсәения» мәдрәсәсе эшли башлый.

Шул чор зыялылары тырышлыгы белән Бреслин фамилияле кешенең шәхси типографиясендә татар хәрефләре булдырыла, татарча-казакъча елына берничә дистә китап басу мөмкинлеге тудырыла. Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман һәм улы Фатих Кәримовлар китап басу эше белән кызыксынгач, бу хыялларын эшкә ашыру юнәлешендә аларга бертуган Рәмиевләр белән Гани бай Хөсәенов беренче ярдәм итүчеләр була. Ахун гаиләсе шәһәргә килеп төпләнгәч тә Бреслин басмаханәсеннән кул көче белән эшләүче станок һәм хәрефләр сатып алына. Һәм татар телендәге беренче китап болар тарафыннан 1901 елның март аенда басылып чыга. Ахун хәзрәтләре исән вакытта, 1902 елның июнь башына чаклы, бу басмаханәдә тиз арада 25 китап дөньяга чыккан, дип белдерә Әбрар ага Кәримуллин. Дөрес, аларның күпчелеге әлегә яшь әдипләрнең башлангыч чор иҗат җимешләре – күләме биш-ун табактан артмаган юка китапчыклар булгандыр.

Беренче авторлар төркемендә Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев даирәсенә кергәннәр дә, сәүдәгәр Хөсәеновлар белән элемтә тотучылар да бар. Мәсәлән, А.Пушкинның «Капитан кызы» һәм Н.Гогольның «Борынгы алпавытлар» әсәрләрен тәрҗемә итеп тә тәҗрибә туплаган Гаяз Исхакыйның тәүге бер-ике үз әсәре Казанда нәшер ителгән булса, тагын берничәсе Оренбургта ахун Кәримов ачкан басмаханәдә дөнья күрәчәк. Гаяз мәхдүмне Казандагы укытучылар мәктәбендә укыган елларыннан (1898-1902) үз итеп күзәтеп килүче, укуын тәмамлагач Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә чакырып китерүче дип, алтмышынчы елларда Гани бай Хөсәеновны искә алырлар иде. Шул хакта аның Казандагы кодасы Садыйк белән язышкан хатларында да искәртелә. Соңрак елларда бу төбәкнең кайбер шәхесләре –мәсәлән Фатих Кәрими һәм аның якыннары белән кискенрәк мөнәсәбәттә булган Г.Исхакыйның да XXнче гасыр башында берникадәр вакыт Оренбургта яшәвен, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе булуын, кимендә ике әсәрен, шул исәптән «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ын шунда иҗат иткәнлеген таныйрга ти-1907 елда Г.Исхакыйның «Зиндан» китабын туплап һәм кереш сүз язып чыгаручы да Габдерахман була. Дөрес, китапка кереш сүз язганда ул үзен асрауга алган үги атасы Әхмәт бай Хөсәенов фамилиясен кулланган. Хәер, әлеге китапны нәшер итү өчен тотылган акча да шул ук Хөсәенов байныкы ич инде.

Ике гасыр аралыгында иң актив иҗат итүче һәм Оренбургка бәйле шәхесләрдән беренче урынны Ризаэддин хәзрәт Фәхретдинов билидер, мөгаен. Берничә дини-тәрбияви әчтәлекле китабы әлгәрерәк язылган һәм чыгарылган булса да, аның күпчелек иҗади хәзинәләре Оренбургта язылган һәм шундагы басмаханәләрдә нәшер ителгән. Бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә аның дистәләп китабы, якын туганнары булган «Кәримовлар басмаханәсе»ндә егермеләбе басылып, төрки дөньяга таралган. (Риза хәзрәтнең бертуган Рәмиевләрнең матди ярдәме белән нәшер ителгән китапларының гомуми саны да авылда XVIII йөз башында ук шул төбәктә танылган мәдрәсә эшләгәнлеге хәбәр ителә. 1913 елда «Шура» журналында бертуган Рәмиевләрнең шәҗәрәсе басылган. Анда аларның бабалары Габделкәримнең, яңа оешa башлаган Эстәрлетамак өязенә күченеп киткәнче, Тайсуганда мәдрәсә тәмамлагач, «шул төбәктәге бер авыл имамы» булуы теркәлгән.

Р.Фәхретдиновның бертуган Рәмиевләр белән аралаша башлаган елларда дини, иҗтимагый-тарихи һәм тәрбияви әчтәлекле «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана» һ.б. хезмәтләре генә түгел, 1898 елда «Сәлимә, яки гыйффәт» исемле романы да нәшер ителгән була. Бераз соңрак аның тагын бер күләмле әдәби әсәре – «Әсма, яки Гамәл вә җәза» бәяне дөнья күрә. Дөрес, ул вакытта әле бик күпләр ул әсәрләрне мөфтияттә эшләүче танылган дин вәкиле, казый Риза хәзрәт язган дип белми. Чөнки ул әсәрләр әүвәл башка кеше исеме, «Гафил бине

шәхесләр

Габдулла» исеме белән басылып чыккан. Әмма шунысы гыйбрәтле, ул әсәрләрнең берсендә шагыйрь Дәрдемәнднең дә бер шигыре – «Үткән көннәр»е киң җәмәгатьчелеккә тәүге тапкыр тәкъдим ителә. Ул дәвердә әле Дәрдемәнд тәхәллүсе белән шигырьләр иҗат итүченең шәхсән кем икәнлеген бик күпләр, шул исәптән әлеге әсәрләр авторы да белми. Уфада һәм Оренбургта даими рәвештә очрашкалап торган мизгелләрнең берсендә, зыялырак халык арасында Риза хәзрәт каләме аша үткән әсәрләр хакында әңгәмәләшүләр куерганрак көннәрдә, ике автор да үз тәхәллүсләренең серләрен ачкан булса кирәк. Әйе, мөфтият казые да ул елларда Оренбург төбәгенә еш килгәләп йөргән. Хөсәенов, Рәмиев ише байлар тарафыннан оештырылган җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрне ачу тантаналарына да, андый уку йортларын ачарга каршы килүчеләрне күндерергә кирәк булганда да монда Ризаэддин казыйның еш килүе кайбер истәлекләрдә теркәлгән.

Ризаэддин хәзрәт, «Тәрҗемәи хәлем» язмасында, әдәби әсәрләр иҗат итәргә керешкән чоры турында мондыйрак аңлатма бирә: «Сәлимә...» илә «Әсма»ны галимнәр җәмәгатеннән булган затлар сөймәде. (Сүз, әлбәттә, дин тарафдарлары, дин галимнәре турында бара.) Әгәр дә минем әсәрем икәнен белгән булсалар, башыма кыямәтләр кубарачаклар иде. Фәкать авторлары билгеле булмаганлыктан, беркадәр сүрелделәр», дип яза хәзрәт.

Аның «Сәлимә, яки гыйффәт» әсәре 1898 елда Казанда, «Әсма, яки Гамәл вә җәза»сы 1904 елда Оренбургта басылып чыккан. Хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф этисенең бу күләмле әдәби әсәрләрен язарга керешүенең сәбәпләрен түбәндәгечә бәян итә. «Әткәйнең күп еллардан соң сөйләгән сүзләре: «Сәлимә...» белән «Әсманы...» язуыма сәбәп роман тәкъдим итү генә түгел иде, бәлки күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып, укучыларга ирештерү иде», дип яза ул «Ризаэддин Фәхретдин» китабында урнаштырылган истәлекләрендә (Казан, 1999).

● Гыйлман ахун Кәримов. Оренбург, 1900 ел. З.Бәширов фотосы.

● Гаяз Исхакый.

Димәк, күпсанлы дини, иҗтимагый-тәрбияви эчтәлекле китапларында әйтеп бетерә алмаган фикерләрнең әдәби әсәр аша халыкка уңышлырак җиткерелүен аңлап эш иткән икән Риза хәзрәт. Сүз уңаенда шуны да искәртик, бөек акыл иясе әлеге алтышар, сигезәр табаклы әсәрләренең, гәрчә нәшер ителгән китапларында «хикәят» дип тамгалануына карамастан, жанр дәрәҗәсе буенча кинрәк, тулырак атамага ия булганлыгын да чамалаган. Хәзерге әдәбият галимнәре дә ул әсәрләрне повесть яисә роман дип билгеләү ягында. Фәкать «Әдипләребез» белешмәлегендә (2009) генә алар «хикәя» дип күрсәтелгән. Күренекле әдәбият галиме Хатип Миңнегулов та Риза хәзрәт эшчәнлегенә багышланган конференциядә сөйләгән докладында ул әсәрләрне роман буларак бәяләгән иде. «Чыннан да һәр ике әсәр дә образларның бирелеше, вакыйгаларның бәян ителеше, идея эчтәлекләре белән роман дип аталырга лаек», дип яза ул шул конференциягә багышланган җыентык битләрендә («Ризаэддин Фәхретдин: мирасы һәм хәзерге заман», 2003, 152 бит). Профессор Мөхәммәт Гайнуллин да «Татар әдәбияты тарихы»ның 2 нче томында урнаштырылган хезмәтендә ул әсәрләрне повесть буларак билгеләп һәм аларны бәяләп, «татар проза жанрын үстерүдә Р.Фәхретдиновның да зур өлеше бар», дип яза.

Риза хәзрәтнең Оренбург шәһәренә күченү һәм бертуган Рәмиевләр белән аралашып яшәү мизгелләрен алдарак бәян итәрбез.

ОРЕНБУРГ ТӨБӘГЕНДӘГЕ ПРОЗАИКЛАР

XIX йөз ахыры белән XX йөз башларында проза жанрында эшләүче язучылар саны бермә-бер арта. Оренбург төбәгенә бәйләнеше булган язучылардан бу чорда шул шәһәрдә яшәп киткән Гаяз Исхакыйны алдарак телгә алдык инде. Шул чорның шулай ук күренекле әдипләреннән булган Фатих Кәрими дә бу елларда бик актив эшли. Ике гасыр аралыгында аның «Салих бабаның өйләнүе» (1897), «Җиһангир мәхдүм» (1900) кебек күләмле хикәяләре, «Бер шәкерт илә студент» (1899) һәм «Мирза кызы Фатыйма» (1901) повестьлары нәшер ителә. (Бер хезмәтендә әдип үзе хәбәр итүенчә, «Мирза кызы...» әсәренең эчтәлегенә нигез итеп ул Исмәгыйль Гаспринский нәселенә бәйле вакыйгаларны ала). Соңрак аның «Хыялмы? Хакыйкатьме?» повесте (1908), «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» әсәре (1904) һәм Балкан сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Истанбул мәктүбләре» китабы (1913) дөнья күрә. Ул шулай ук бер дистә чамасында дәреслек, ике дистәдән артыграк исемдә фәнни-популяр китап һәм тәрҗемәләр авторы да.

● «Хөсәения» мәдрәсәсе җитәкчеләре, мөфтият кунаклары һәм иганәчеләр төркеме. Утыралар (уңнан сулга): мәдрәсә башлыгы, имам-хатыйб Габделгалим Дәүләтшин, Өфедән килгән казыйлар Хәсәнгата Габәши, Гыйниятулла Капкаев, Нурмөхәммәт Мәмәтов, басканнар (сулдан уңга): иганәче байлардан морза Мәхмүд Госманов, фабрикант Хәсән Акчурин, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд, морза Гайсә Еникиев (Әхмәт бай Хөсәеновның вакыф идарәсе башлыгы), мәдрәсәнең ул чордагы иганәчеләр башлыгы Мәхмүт Хөсәенов, язучы Фатих Кәрими, морза Закир Хәеров.

Әдипнең Совет хакимияте чорында башкарылган, әмма нәшер ителү барышында туктатылган тагын бер хезмәтен искә аласы килә. Әйе, ул вакыйга автор өчен бик уңышсыз тәмамлана. Бүген аны да искә алу кирәктер. Әдипнең ул хезмәте «Рухият» фонды тарафыннан 2000 елда нәшер ителгән «Фатих Кәрими» китабындагы тәрҗемә хезмәтләре исемлегендә дә теркәлмәгән. Вакытында басылып чыкмавы сәбәпле хаклы рәвештә ул анда кертелмәгән. 1992 елда миңа Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романын басмага әзерләү бурычы йөкләнгән иде. Ул китабына олуг әдипнең Мәскәү түрәләренә атап русча язылган күләмле бер хатының тәрҗемәсен дә тәкъдим иттеләр. Шул хатында әдип алда исеме аталган шушы романны русчага тәрҗемә иткән Фатих Кәрими хезмәтеннән канәгать булмавын белдерә. Аның кульязмасын типографиягә төшерүгә мин каршы киләм, ул әсәрне рус әдәбиятын яхшырак белүче башка кеше тәрҗемә итәргә тиеш, ди. Ф.Кәрими тарафыннан тәрҗемә ителгән бу хезмәт шул рәвешле юкка чыгарыла. Әмма без аның шундый эшкә талпынып караганлыгын истә тотарга тиешбездер, мөгаен.

(Дәвамы киләсе санда).

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.

Мәдәни җомга
4 август
№30, 2023

(Дәвамы. Башы 29 нчы санда.)

– Менә барын да күңелдән өйрән! Икенче Гайшә апаң кайтканда бер дә ул җырлаганны көтеп тормыйча үзең җырлап күрсәтерсең диде дә, бу сиңа сабыйлык хатирәсе! Мине дә, Гайшә апаңны да онытма! – диде.

Ул бездә бер генә төн йоклады, дүшәмбе көн мин мәктәпкә барырга торганда, алар китәргә җыенган иде инде. Әти Казаннан кайткач:

– Бу бик кызык шәкерт икән, – ди. Мин:

– Мәгъзум безнең хәзрәт бик сызланып торыгыз!» – диде дә миңа карап: «Улым былтыр үзеңә Тукай абыеңның рәсемле китабын биргән абыеңны хәтереңнән чыгармадыңмы?» – диде. Мин:

– Юк, без ул китапны көн саен кулга алабыз, ул бит аны биргәндә – минем истәлегем итеп укы! Гайшә апаңны да, мине дә хәтерлә, – дип бирде, – дидем.

– Менә алайса шул шәкерт абыең быел да кайткан булган, былтыр минем белән барган кебек, Казанга кайтып барганда каты салкында бик каты өшеп үлемнән аз гына калган, хәтта бер күз алмасы да каткан, башка җирләрен больницада куйдым, алар хәзердә шушы көнгә кадәр минем хәтеремдә саклана.

– Бу җирдә без нишләп туктап калдык? Сине бит моннан тагын килеп куалар диде, әйдә әле коерыкка барып карыйк, анда мишәр бабай янында минем әйберләр бар, шунда берәр арт теркәлерлек урын тапмабыз микән? – дигәч, мин шул минутта бәхеткә ирешкән төсле булып калдым. Без койрыкка барганда бабаебызның башы, өзек башны мунчала белән якага бәйләп

Зыя ЛАТЫЙПОВ

балакаем дип кенә торган туган анасы да качыра икән, – диде.

Мин: «Бу тормышта ишетелмәгән сүз, һич төшенмәдем», – дидем.

– Минем үз уемча да тормышта беренче булган хәлдер бу! Әле үзем дә төшенеп бетә алмыйм, дигәч, миңа тагын да гаҗәбрәк тоелды, мин тагын да сабырсызлана төштем. Балаларчарак итеп, «Дускай! Әйтеп кенә бирмисеңме? Мин тынычланыр идем», дигәч, минем сәфәрдәш егетем: «Бу шактый озын әңгәмә, әнә көймәгә хуҗа булып алсак, мин сиңа иркенләп төннәр буе сөйләп аңлатырмын!» – диде.

ПАРОХОДТА ОЧРАШУ

коры сырхау белән авырый, болай булса озакка бармас, әллә үзеңне муллалыкка сорыйммы? – дигәч, ул миңа болай диде:

– Мин мулла булырга җыенмыйм. Мулла булсам да сезнең авылга бармас идем, сезнең авыл бик начар чиргә тарыган булган икән! – диде.

Мин ул сүзне ишеткәч каттым да калдым, азрак уйланып баргач «җавапсыз калу ризалык галәмәте, бу нинди начар чир дип уйладым да: «Шәкерт, бу сүзне нәрсәгә таянып әйттең?» – дидем.

Шәкерт бер дә каушап төшмәде:

– Сезнең авылга ишаннар чире кергән, әгәр шушы хәлдә барса, халкыгызның купчелеге Тарханның Нури ишанына кул биреп җенләнеп бетәр, әллә нинди фаҗигаларга сәбәпче дә булыр иде әле.

– Андый ук начарлыкларга батырчылык итмәсләр, тик шулай да актык сыерларын суеп, балаларын сөттән мәхрүм иткән берничә мөрит бар инде, – дигәч ул миңа, үзегез белән нәрсә булып узганын хәтерлисездер бит? Каюм дигән энегез ни өчен кул күтәрде, нинди начарлык эшләдегез? – дигәч мин: «Кайдан ишеттегез сез мондый начар хәбәрне?» – дип сорадым.

– Начар хәбәр тиз тарала ул. «Җирнең дә колагы бар», – дип бушка гына әйтмәгәннәр, сез дә бик акыллы сүз әйткәнсез!

– Әйтелде шул Мәгъзум, миңа да алай каты әйтеп ташларга кирәкмәс иде дә бит, бусагаңа килгәндә кул бир, изгеләр сафына кер, кешеләр ничә йөз чакырымнан эзләп киләләр. Синең бусагаңа килгәндә гафил булып каласың, дип ачуымны китерә биргәч, мин үзем кул бирү түгел, кул бирүчеләрне дә хәрап буласыз, сыер-сарыксыз каласыз!

Әнә ничәвегез сыерын суеп ашатып, балаларын ач калдырды. Син дә шуны эшлиячәксең. Әнә, дәү абзый салкын кышкы көндә ишек төбендә өч тиенгә читек ямап, туңып утыра. Син шуны күреп абзыйга түр сәкеңнән бер намазлык җәйдерерлек урын бирер идең! – дигәндә, Каюм «Җитте, артык чыдар хәлем юк!» дип якаман тотып буып үтерә башлаган иде. Шул, ярый әле кызлар өйдә вакыт булды, ике кулына икесе салынып кулларын бушаттылар! – дип сөйләгәнемне тыңлап барды да, «Әнә бит, шушы халык янында дөрес юлга өндәгән мулла яши аламы? – диде шәкерт.

Дөрес фикерле икән, дип эти Казаннан кайткач шул сәфәрдә сөйләгән сүзләрен хикәят итеп сөйләп утырган иде. Ул хәл шулай сөйләнде дә калды, җәй үтеп китте, тагын кыш килде, эти һаман да шул элеккеге кәсебендә. Әти Казаннан кайткан йөкне бушатып базар итеп кайткач, кичке аш янында безгә «Бер яңалык сөйлим, тыңлап

терелткәннәр, тик бер күзе генә күрми калган, – диде.

Безнең әни барыбыздан да алда:

– Әй, бәгърем, алмадай егет, әти-әнисе ничек түзә икән? – дип җылый башлады, аны әтигә Халисә апаның анасы Гайнавал абыстай сөйләп кайтарган.

Шуны сөйләп бетергәнче әлеге яшь үсмер егет минем күз алдымнан китми басып тора бирде.

Ул миннән «Тагын да китапларың юкмы? – дип сорагач, мин «Алар бездә бер дөя йөге булыр, мин берсен генә үзем белән алдым», – дидем.

Шул арада әлеге тынычсыз күн кәпәч тагын минем яныма килеп туктады, ул әйтмәстән үк аның нәрсә әйтәсен мин белеп торам инде. Ул миңа «кнехт-кнехт» дип нәрсәдер сөйләнгәч, минем кулдагы бу сурәтле кечкенә балалар китабын күреп, «нәрсә укыган булып утырасың», дип сөйләнә икән дип уйласам, ул әлеге мин утырган куш чуен букәнне пароход теле белән «кнехт» дип әйтәләр икән, ул миңа «тор, малай», дип эндәшә икән! Кнехт өстеннән алла сакласын, берәрсе суга кагып төшермәсен, – ди икән.

Ул сүзне миңа бер татар кешесе төшендереп, болай диде: «Бу син утырган чуенны «кнехт» дип әйтәләр, аңарга пароходны туктатканда чалка урап куялар», –дигәч, мин «Аны бая цемент түгән җирдә дә ишеткән идем, бу чуен кош букән «кнехт», бу юан аркан «чалга», бу озын дилбегәне «логсн», диләр икән. Мин боларны үземнең кечкенә хатирә дәфтәремә теркәп куйган төсле, аркасына салынып төшкән, йоклый иде.

Чынлап та бабай янында икебезгәдә кысылсак та урын табылды, менә шатлык! Иптәшем мине утыр-утыр, дип кыстаса да, мин аны утырттым, ул миннән зуррак та һәм башлап урынны да ул алды. Без азрак тозсыз сөйләштергәләп утырган арада бабай да уянды, безнең акрынрак сөйләшеп утырган сүзне колагын салгалап тыңласа да ишетә алмады, ахры, ике кулын идәнгә терәп, күрше хатынга таба шуышып, миңа урын күрсәтте. Рәхмәт әйтеп мин дә утырып алдым, мин ары-бире күз йөртеп коерыкка бастырып куйган бүрәнәгә таза чылбырлар белән дүрт җиреннән таккан көймәгә күзем төшеп, «Дускай, әнә иркен урын кайда? – дигәч, иптәш: «Карале әй, чынлап та әйдә керик тә ятыйк!» – дигәч, мин «Юк хәзер үк ярамас, теге күн кәпәч тагын килеп җитәр, ул мине танып бетерде инде. Кичкәрәк, берәү дә бездән алда эләктереп куймаса? – дидем. Иптәш:

– Мин дә шуны уйлыйм шул, ярый инде бәхет гере безнең якка басса, – дип куйды да, шактый озак сүзсез утырды. Мин сүз башлап:

–Кара әле дускай, мине фәкыйрьлек, ятимлек, чалыш өй аерды, хәер үги ана янында өйдә дә сыеп булмый инде, – дидем.

Егетем сүзсез генә пароход артыннан кайнап ыргылып күбекләнеп күтәрелгән дулкынга карап барды да, миңа әйләнеп:

– Бу дөньяны аңламассың, дускай, берәүне үги ана качыра, берәүне өзелеп

Мин төннәр буе дигәч бу сүзнең бер-ике сәгатьтә генә сөйләп чыга торган хәл булмавы үзеннән-үзе аңлашылып тора, кашки көймәгә генә башка кешеләр хуҗа булып куя күрмәсен тагын, бабай янында кысылып утырып мондый серле әңгәмәне аңлашып буламыни. Тик тизрәк теге сары сакал авышса да, утлар яндырылса икән, аннан соң әллә ни актарынмаслар иде.

Мин хәзер сәфәрдәшемә бер сүз дә әйтергә куркып торам, аның күңеле тирән рәнҗү белән капланган, җаны кыйнала иде, аны бәлки карап кына торган кадерле балалары булуга карамастан, вакытлы рәвештә күз алдыннан югалып-китеп торуга мәҗбүр иткән берәр сәбәп булгандыр? Бәлки мин уйлаган уйларның берсе дә дөрес түгелдер?

Мин шушы турыда төрле хыялларга чумып утырганда әлеге сары сакал, идән юа торган саплы пумаласын иң башына күтәреп чапырдатып су агызып килде дә утырган-яткан юлчыларны урыннарыннан кузгатып идәнне юа башлады. Юлчылар – кайсы капчыгын, кайсы сандык сыман ящикләрен кулларына күтәреп аякка басты. Сары сакал идәнне сулап чыкты да пумаласын сөйрәп китеп юдыммы, нишләттe, яңадан иңбашына күтәреп килде дә яңадан бер мәртәбә ышкып-ышкып корытып алды да пумаласын тагын да идән буйлап өстерәп китте.

Үзләренең кулга күтәреп торган әйберләре белән халык бер-беренә карашып, «инде утырсак ярый микән?» – дигәндәй үз урыннарына урнаша башлады. Минем сәфәрдәшем бая сөйләшкәндә биргән вәгъдәсен хәтереннән чыгармый булса кирәк. Ул бер дә көймәдән күзен алмый.

Ул арада пароход озын гына сузып уфлап кычкырды да, бер зур гына пристань янынан узып, күбекләр актарып, койрыгы белән зур дулкыннар куптарып, бер биек озын булып агып барган салны коендырып, агып узган якка, үр ягына борылып, яңа карап узган пристанегә әйләнеп килеп туктады. Сал өстендәге халыклар бик каты кычкырып, йодрык күрсәтеп калды. Күршеләр юган идәнгә утырып алгач та, чәйнек-кружкалар шалтырата башлады, безнең бабай да безгә карап куя, ә без алдан көймәгә эләгеп алып чәйне аннан соң эчәр идек, дип өметләнәбез. Иптәш әйтә:

– Әйдә, аллага тапшырып кунаклыйк, – ди. Мин әйтәм:

– Дускай озак көттек, әз генә калганда эшне бозып ташларбыз, сабырсызланмыйк, сабырсызлык күп эштә зарар китерә!..

Ташкент, 1968 ел.

Республикабызда «Сугышчан дан клубы» ассоциациясен җитәкләүче Михаил Черепанов Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбызны ачыклау һәм татарстанлыларның сугышчан батырлыгын пропагандалау буенча бәһаләп бетергесез эшчәнлек алып бара. Ассоциациянең эзләнү төркеме республикабыз хәрби комиссариатлары аша чакырылып, Германияне җирен фашизмнан азат итү алып барган яулар барышында һәлак булган 13721 якташыбыз исем-фамилияләрен ачыклап өлгергән. Әлбәттә, бу тулы исемлек түгел, еллар уза-уза, фашизмны юк итүдә батырлык күрсәткән якташларыбызның саны һаман артыр әле. Берничә каһарман якташыбызның гына исемнәрен телгә алып узыйк.

Берлинны яулаган татарлар

Дошман оясы саналган Берлин каласын фашистик рейхтан азат итү өчен һөҗүмне совет гаскәрләре 1945 елның 22 апрелендә башлый. Шушы тәүге көндә үк Арча районының Түбән Әҗәк авылында туп-үскән **Гарәпша Шаһимәрдәнов** Рейхстагтан 5 чакрымдагы Густав Адольф урамына иң беренчеләрдән булып керә. Шушы урам бәрелешләре барышында расчетлары белән бергә дошманның 3 тубын һәм 50 гә якын гитлерчыны юк итүгә ирешә. 24 апрель көнне Шаһимәрдәнов инде үзенең рота сугышчылары белән бергә дошманның 45 танк һәм үзйөрешле орудиеләрен кулга төшерә. Якташыбызны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп рапортлар юллыйлар, ләкин Гарәпша Алтын Йолдызны алу бәхетенә ирешми.

Серия Т
№ 07771
Шахимарданов
(фамилия)
Гарапша
(имя)
Шахимарданович
(отчество)
Б-795359
(личная подпись владельца билета)
Военный билет выдан
м. п. 9 октября 1948 г.

I. ВОЕННО-УЧЕТНЫЕ ДАННЫЕ
1. Род войск (служба) бронетанковая и механизированные войска
ВУС № 39
2. Воинское звание Капитан
3. Запас Первого разряда
4. Должность Командир танковой роты
5. Должен состоять на учете по 31 декабря 1965 года

Гарәпша Шаһимәрдәновның хәрби билеты.




НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Татарстанның Балтач районындагы Янгул авылында туып-үскән **Габдулла Гарифуллин** мәктәптән соң Донбасска чыгып киткән һәм анда фабрика-завод өйрәнчекләре курсында һөнәр үзләштергән була. Аннары Чиләбе трактор заводында хезмәт куя. 1942 елның августында аны фронтка чакыралар, ул ноябрь аенда Волхов фронтына эләгә. 1943 елның гыйнварында Ленинград блокадасын өзү өчен яуларда гитлерчыларның 5 дзотын, 2 пулеметын, танкка каршы тупны һәм 60 ка якын солдатын юк итүгә ирешә. Берлин диварлары янына ул 1 нче Белорус фронтының 5 нче удар армия составындагы 54 нче җиңел артиллерия полкының орудие башлыгы, ике Дан орденына ия сержант дәрәҗәсендә килеп җитә.

Берлинга якынайгач та, Одер елгасы аръягында плацдарм яулаганда, Гарифуллинның расчеты 5 пулемет, сугыш припаслары тутырган 2 автомашинаны, күзәтү пунктын һәм 60 ка якын гитлерчыны юк итә. Берлин урамнарында янә 9 пулемет, 8 миномет һәм 30 дан артык дошманны юк итәләр. Гарифуллин шул 23 апрель көнендә Берлин урамнарының берсендә өй түбәсенә Кызыл байрак элеп куя.

Гарифуллинны май аенда ук Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Якташыбызны данга күмгән Указ 1946 елның 15 маенда гына игълан ителә. Демобилизациялəнгәч, Габдулла янә туган авылына кайта, анда авыл советы рәисе һәм соңрак «Большевик» хуҗалыгының рәисе булып эшли. 2002 елда туган авылында җирләнгән.

Габдулла Гарифуллин портреты һәм аны бүләкләү рапорты.

Казахстанның Урал өлкәсендәге Березов районының Черкасово авылында туып-үскән 19 яшьлек татар **Георгий Булатов** 1945 елның 30 апреле көнне 14 сәгать 25 минутта Берлиндагы Рейхстаг диварына Кызыл байрак элеп куюга ирешә. Ул бу вакытта 150 нче укчы дивизиянең разведчиклар төркемендә була. Шушы байракны соңыннан күп җирдә Җиңү байрагы дип күрсәтеп тә йөриләр. Әмма ни үкенеч, милләттәшебезгә Советлар Союзы Герое исеме бирелми.



Григорий Булатов (алда) үзенең сугышчан иптәшләре белән Рейхстаг янында.

Шушы урында өстик. Германиядә һәлак булган 13721 якташыбызның 7320 се – әсирлектә, 206 сы яраларыннан вафат була. Берлинны штурмлаган чагында гына да Татарстаннан 368 солдат һәм офицерның гомере өзелә. Аларның 182 се – татар фамилияле.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

АВЫЛ КӨНЕ ҺӘМ...

Гаҗәп килеп чыкты: без «Мәдәни җомга» битләрендә июль аеның дүрт санында Актаныш районының Иске Байсар авылы турындагы тарихи язманы нәшер итеп кенә тәмамлаган идек, нәкъ бер тәүлектән соң, 29 июль шимбәсендә ошбу туган нигезебезгә кунакка чакырдылар. Иске Байсар үзәгендә авыл көне уза, авылыбыз исә әүвәл Кыргыз һәм Бүләр олысларының бер түбә-аймак башы, аннары үз исемендәге волость үзәге буларак билгеле. Анда ким дигәндә бер гасыр дәвамында күрше төбәкләрдә дан алган базар-ярминкәләр уздырылган, хәтта Минзәлә каласының урыс байлары да биредә кирпеч кибетләр төзеп куйган.

Менә шул данлыклы чорны хәтердә яңарту өчен авыл көнен борынгы базарлар рәвешендә билгеләп үтәргә булганнар. Күрше район һәм авыллардан күчмә кибетләр, сәнгать осталары, хәтта сабыйлар яратып катнаша торган резина таулар, сикерү манежлары да чакырып китергәннәр. Авыл үзәге иртәдән диярлек шаулап-гөжләп, аерым җырчы-биючеләрне яңадан-яңа сәнгать коллективлары алыштырып торды.

Чыгышлар барышында, әлбәттә, Байсар авылының гаҗәеп бай тарихы турында да сүз кузгалды. Без 7 нче июль көнне нәшер ителгән санybызда ук 1653 елгы тарихи документны бер ноктасына да тимичә ачып салдык. Шул елның 5 мартында Уфа провинциясе канцеляриесе Бүләр авылында гомер итүче 80 яшьлек карт Байсар Күзәш улының воевода Иван Франзбеков исеменә язган үтенечен терки. Үтенечтә Байсар-карт үзенең бу авылда 80 ел буе тиешле ясакны бер елда да өзмичә, даими рәвештә Уфага – 10 сусар, Казанга 2 сусар тиресе һәм 5 батман бал күләмендә түләп килүе турында бәян итә һәм, хәзер инде бик өлкән яшьтә булуы сәбәпле, әлеге ясак күләмен бүгенге Мөслим районының Турыш авылы крестьяны Айтуган Сабаков (Субәков) белән бүлешеп түләргә рөхсәт бирүләрен сорый. Нәкъ шушы тарихи документ безгә Бүләр-Байсар авылының чишмә башын 1573 елга илтеп бәйләргә нигез бирә. Димәк, агымдагы елда Иске Байсар халкы үз авылларының 450 еллыгын билгеләп үтәргә хокуклы. Дөрес, аңа Байсар авылыннан 1738 елның 9 сентябренда төзелгән килешү буенча 5 чакрымда барлыкка килгән Мәчти-Наратлы, 1860 еллар үрендә Сөн елгасы буйлап ике чакрым югарырак урнашкан Яңа Байсар, нәкъ шул ук елда Башкортстандагы Яңавыл районына күчеп киткән һәм анда янә Байсар исемле өр-яңа авыл

БОРЫНГЫ КАБЕРЛЕК

корган һәм 150 ел буе гомер иткән, шулай ук 1927 елда иске авылдан аерылып, Сөн аръягында Чишмәбаш саласын нигезләгән якташларыбызның да тулы хокукы бар!

Авыл ирләре бервакытта да ил өстенә килгән яисә төбәк аша узган тарихи вакыйгалардан читтә качып калмаган. Безнең төбәк бабайлары 1695 елда Петр патша Кара диңгезгә чыгу өчен оештырган Азов походында, 1757 елда патшабикә Елизавета фәрманы буенча Пруссиягә каршы походта катнашкан һәм Егерсдорф крепосте янындагы яуда тулы җиңүгә ирешкән. 1771 елда Әби патша фәрманына буйсынып, бабаларыбыз үзләре өчен тамчы да кирәксез яңа походта – азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән Польша крестьяннарының фетнәсен бастыру өчен дә юл йөргән. Шуннан кайтып җитүгә үк бар Россия империясен дер селкеткән Пугачев явына да күпләп кушылганнар, байсарлылардан 31 крестьянның исем-фамилиясе тарихи документларга кереп калган. Аннары байсарлылар да, Минзәлә өязенең зур күпчелек җайдаклары да 1812 елгы Ватан сугышы походларына кузгалган, кайберләре Парижны штурмлауда да катнашып, үзен данга күмгән. Ни үкенеч, аларның исем-атлары берниндидер һәйкәлләрдә һәм тарих дәреслекләрендә дә урын алмаган шул, әлеге походлардагы иң зур данга өлкән агай вәкилләре ия... Әмма Байсар ирләре узган бәрәкәтле дә, данлыклы да юлны онытмаска тиеш, аны үсеп килгән яңа буын хәтеренә сеңдерергә кирәк, авыл үзенең 450 еллыгын бәйрәм итсә, шул вакыйга үзе үк олы сабак һәм шөһрәт тә була алыр иде...

Аннары... без кайткан көннәрдә туган төбәгебез өр-яңа бер данга да ия булып өлгергән иде инде. Байсардан бер чакрым ераклыкта, Сөннең аръягында, икеяклы Казан-Уфа трассасын төзүчеләр Чишмәбаш авылы күршесендә генә моңа кадәр һичкемгә дә билгесез борынгы каберлек урынын ачыклаган. Бу хакта мәгълүмат узгынчы шоферлар аша социаль челтәр битләренә таралган, гәрчә һичнинди аңлатма булмаса да, ул каберлекне әллә ничә төрле юрама һәм имеш-мимеш белән тутыра башлаганнар. Шунда кадәр кайткач, билгеле ки, без фәкыйрьләребез дә читтә генә гамьсез кала алмадык, ул каберлек чиген кат-кат урап чыктык.

Бу каберлек урынын әле 2021 елда ук ачыклаган булганнар, ә икеяклы трасса сузу Чишмәбашка кадәр килеп җиткәч, җәй уртасында тарихи урынга археологлар бригадасы да килеп җиткән. Юл төзү эшләре белән «Волговятскуправтодор» идарәсе җитәкчелек итә, ә каберлек урынында казу үткәрүне Казан каласындагы «Центр-Эпир» оешмасы үз өстенә алган. Археологларны төрле кала энтузиастларыннан туплаганнар, башлыклары – Стәрлетамак шәһәре тарихчысы Максим Стародубцев. Каберлек тарихи казулар картасында «Чишмәбаш стоянкасы (тупланышы) –1» дигән тамга да алган инде...

Бу – элек Каравыл тавы дип аталган калкулыкка менә торган тау итәгенең нәкъ уртасы. Мәктәптә укыган елларда, теодолитлар алып килеп, Каравыл тавының Байсар үзәненнән 92 метр биеклектә урнашкан булуын ачыклаганыбыз бар иде. Каберлек ярты юлдагы бер җиңелчә калкулык сыртында урнашкан. Өске якта катнаш урман терәлеп тора. Аскы якта – Сөн елгасының элек аккан урыны. Янәшәдә генә ике көчле чишмә. Ниндидер узгынчы ыру яки нәсел берлеге тукталып гомер итү өчен бик тә кулай урын. Ауга йөрү өчен – урманы, мал көтүен туплау өчен – иркен ялан, балык тоту өчен Сөн елгасы һәм эреле-ваклы дистәләгән күлләр бар.

Тарихта «Бронза гасыры» дип билгеләнгән чорның азагында, безнең эрага кадәр 2 нче гасырда менә шушы калкулыкта борынгы бер ыру яшәргә тукталган. Димәк, әлеге тарихи каберлеккә ким дигәндә 2200 елдан артык. Монда яшәп киткән борынгы кешеләргә безнең борынгы болгар яки татар бабаларыбызның һичнинди мөнәсәбәте юк (бәлки, шуңадыр да Казан каласыннан яки андагы фәнни институтлардан бирегә сыңар тарихчы да килмәгән). Бу төбәккә иң тәүге болгар бабаларыбызның да фәкать VIII гасырда, ә татар ыруларының XIII-XIV гасырлар чигендә генә килеп урнашуы мәгълүм. Гоман корып караган очракта, 2200 ел элек биредә тупланып яшәгән кешеләрне фин-угор халыкларының бабалары, дип тәгаенләү мөмкин. Әмма асылы шулаймы, моны шушында табылган скелетлар, бизәнү җиһазлары, бронза аел һәм бронза ук очлары, эш һәм сугыш коралларының калдыклары аша антропологлар, биологлар һәм тарихчылар гына ачыклап бетерердер...

Без археологлар башлыгы М.Стародубцев белән каберлек урынында.

Тупланыш урыны бик кечкенә түгел. Элекке Сөн елгасының сөзәк яр буенда хуҗалык тораклары урнашкан булган, ул урыннан күбесенчә чәрдәкләнеп беткән мал сөякләренең калдыклары һәм эш коралларының кайбер кисәкләре чыга. Яшәгән шалашлары яки борынгы йортлары кайсы тирәдәрәк урнашкандыр, археологлар һаман тап булмаган. Ә каберлек – әлеге тупланышның өске ягында, Чишмәбаш авылына якынрак ягында. Тупланыш урынын, җепләр сузып, кишәрлекләргә бүлеп чыкканнар. Кайбер кишәрлекләр урыныннан хәтта өчәр кабер урыны ачыклана. Каберләр ниндидер афәт, ягъни талау яки җимерү-янгыннар күрмәгән шикелле. Борынгы кешеләр бик сай итеп, кайбер урыннарда 50-60 сантиметр тирәнлектә генә күмелгән. Күпчелегенең кул-аяклары, барча әгъзалары исән-сау. Бер күмәк каберлектән генә баш сөякләре булмаган биш җәсәд табылган. Гәүдәләре бик тә пөхтә итеп тезелгәнгә күрә, күпләр аларны башларын чабу ысулы белән җәзага тартылган әрвахлар, дип юрый. Асыл сәбәпләре нидер – аны кем генә ачыклый алыр икән?..

Археологлар ике-өч гектар чамасы мәйданны бүлеп алган, көн дә ким дигәндә 10-15 чамасы кабер урынын ачыклыйлар. Утыздан артык мәет җәсәде чыккан, тагын 30 да, 50 дә табылуы мөмкин. Каберләрнең кайберләрен агач бура сыман корылма белән дә уратып алганнар, анысы Пьянобор культурасына туры килә. Биредәге археологлар Әгерже районындагы элекке Пьяный Бор, Татарстан белән Башкортстан чигендәге Иске Кыргыз авылы янында да шушындый ук каберлекләрдә мондый үрнәкләргә тап булганнар. Ягъни, әллә нинди чит-ят халык түгел, биредә дә фин-угор яки аларга тугандаш берәр ыруның вакытлыча яшәү урыны булганлыгы ачыклану мөмкин...

Милләтемә яки нәселемә һичнинди мөнәсәбәте булмаса да, борынгы каберлек урыны барыбер шомландыра. Мәктәп елларында без шушы каберлек өстеннән чана яки чаңгы шуа идек. Шушыннан 300-400 адым биектәрәк кенә 2-3 ел чамасы район пионер лагере, ә Сөн елгасы буйлап ике чакрым түбәндә ел саен колхозның пионерлар лагере эшләп торды. Шушы тау сыртына менеп, ел саен карагат, чия, бөрлегән, камырлык, юа, җир җиләге, хәттa гөмбә җыйдык. Шушы тау сырты аша узып, ел саен урманда миллек белән печән әзерләдек. Һәр адымда тарих эзләре җәйрәп ята икән, дип кем уйлаган?..

Вахит ИМАМОВ.

Автор фотолары.

Ачыла барган каберлекләр рәте.

Серле Әгерҗе

Әллә Казаннан шактый читтә булганга, әллә кара урманнар арасына урнашканга, әллә шушыннан Себер тайгалары башланганга, каторжаннар юлы үткәнгә, Әгерҗе төбәге минем өчен гел кырыс һәм серле булып тоела иде. Халкы да казан татарлары һәм мишәрләр кебек түгел, күзгә кереп, чәчрәп тормыйлар, ниндидер тыйнак, моңсу басынкылык хас аларга... Бәлки ар-чирмеш кебек урман халыклары белән гасырлар буе янәшә яшәү дә холык-фигыльләренә шулай тәэсир иткәндер. Әмма Әгерҗе төбәге татарларында эчке үҗәтлек көчле, максатка һәм нәтиҗәгә ирешү өчен, алар дәшми-тынмый гына ахыргача бара. Һәрхәлдә, минем белән аралашканнары шундый.

● Авыл сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Әхмәтҗановның өр-яңадан тергезелгән йорты.

Ә бу төбәккә мин инде егерме елдан артык килеп йөрим, күп тапкырлар Иж-Бубый авылында фәнни җыеннарда булдым, әле узган ел ахырында гына да Әгерҗенең үзендә, Тирсә, Ямурза, Уразай авылларында очрашулар уздырдым. Әлбәттә, бу якларга һәр килүемдә төбәк тарихы, танылган шәхесләр язмышы белән кызыксынам. Мин Әгерҗе тарихын язарга җыенмыйм, чөнки бу төбәкнең үз елъязмачысы бар, ул – галим Раиф Мәрданов. Ул Ирек Һадиев белән берлектә, бу районның борынгы кабер ташларын өйрәнде, төбәк тарихы буенча китаплар тудырды. Аларның эшен язучы Чыңгыз Мусин дәвам итте, Әгерҗе төбәге тарихы турында саллы китап чыгарды. Райондагы кайбер татар авыллары турында да инде документаль китаплар дөнья күрде: Тәнзилә Ибраһимованың «Чал тарихлы Уразаем», Шәфкать Халиковның «Без Балтач Мәмәт нәселеннән», Габдулла Галиевның «Кырынды авылы тарихыннан хатирәләр», Эльза Сибгатованың «Бөек Себер юлында Биектау» китаплары. Галим Раиф Мәрдановның «Тарихта тибрәлгән Тәбәрле» китабы үзе аерым бер урында тора, анда бу төбәкнең бөтен тарихы һәм язмышы чагыла кебек. Шулай да, бу якларга һәр килүемдә мин төбәк тарихы буенча үземә яңалыклар ачам. Әйтик, Тирсә авылы үзенең гыйсъянчыл тарихы, баш күтәрүләре белән гыйбрәтле, Ямурза исә бүгенге динилеге белән игътибар яулады, югыйсә, заманында бу авылда да көчләп чукындырулар булган.

Менә инде егерме елдан артык Себергә бөтен сәфәрләрем Чаллыдан Әгерҗе аша үтте, киткәндә дә, кайтканда да мин анда туктала идем. Биредә мине милләттәшем, фикердәшем, утыз ел буе милли хәрәкәттә бергә булган Вәсилә Хәкимова һәм аның гаиләсе кадерләп каршы ала һәм озатып кала иде. Вәсилә ханым – озак еллар Удмуртия дәүләт педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты укыткан тәҗрибәле мөгаллим, ул шулай ук Әгерҗедә һәм Ижауда көллиятләрдә, мәчет-мәдрәсәләрдә гарәп теле дә укытты. Хәзер исә, лаеклы ялда булуына карамастан, Иж-Бубый урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, Бөтендөнья татар конгрессының Әгерҗе районы бүлеген җитәкли. Мин дә Вәсилә ханым Хәкимованың чакыруы буенча узган кыш Ижауда һәм Әгерҗе районында очрашулар уздырдым, быел җәй исә Иж-Бубый авылына, мәктәп укучыларының мәчеттә оештырылган җәйге җәйләүләренә укытырга килдем.

Дөрес, моннан берничә ел элек Иж-Бубый мәчетендә балаларга җәйге җәйләү оештырып караганнар, әмма ул озын гомерле булмаган. Менә без дә, шушы тарихи татар авылында, яңадан мәчеттә булса да, балаларга ислам дине нигезләрен аңлатып карарга алындык. Заманында мәдрәсәләре гөрләп эшләп торган, Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә Буби-Нигъмәтуллиннары белән милләт тарихына гомерлеккә кереп калган Иж-Бубый бит ул!

Ни кызганыч, Әгерҗе районы мәгариф бүлеге җитәкчесе моңа башы-аягы белән каршы булды, Иж-Бубый урта мәктәбе дә ярдәмгә килмәде. Бары тик «Бубилар мирасы» фондының җитәкчесе, иганәче Искәндәр Җиһангәрәев ярдәме белән генә, район хакимияте безгә мәчеттә җәйге җәйләү уздырырга рөхсәт итте. Искәндәр шушы авыл кешесе һәм Иж-Бубыйның элекке данын торгызуга күп көч куйган шәхес, шуңа күрә аның сүзе Казанда да, Әгерҗедә дә үтә. Балаларны ун көн буе тәм-томнар белән сыйлау да аның акчасына булды, ул аларны Удмуртиягә җәяүле походка да алып барды. Без исә Вәсилә ханым белән бар көчебезне балаларны укыту эшләренә бирдек.

Әмма без ялгыз түгел идек, янәшәбездә һәр көнне диярлек Әгерҗе районы имам-мөхтәсибе Габделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин булды, ул балаларны район үзәгендәге «Нур» мәдрәсәсенә алып барып, кунак та итте. Казаннан гаиләсе белән махсус килеп, Рөстәм хәзрәт Ясәвиев балаларга дәрес биреп китте, ул үзе дә шушы районнан икән. Безгә Иж-Бубый авылында урнашкан музей хезмәткәрләре дә зур ярдәм күрсәтте. Авылда ике музей бар, аның берсе мәктәптә урнашкан, икенчесе татар бае, иганәче Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов нигезендә торгызылган. Балалар бу музейларның икесендә дә булды, Раиф Гәрәев, Нурия Мәннапова, Алсу Хисаметдинова аларга Бубилар тарихын да, мәдрәсә тарихын да җентекләп аңлатты. Авыл тарихы музее җитәкчесе, Иж-Бубый тарихын кабат торгызу өчен күп көч куйган Раиф Гәрәев балаларны авыл буенча йөртеп, аларга узган гасырлардан калган һәр бинаның тарихын сөйләде, туган якка мәхәббәт менә шундый чаралар аша да уяна бит!

Мин исә җәйге җәйләүгә йөрүче балаларга әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, әдәп-әхлак, психология буенча дәресләр бирдем, Коръән һәм хәдисләргә, шулай ук дин темасына балалар өчен үзем язган китапларга да таяндым. Ә ул китаплар бишәү – «Сәнгать дөньясына сәяхәт» (1989),

«Бәхет ачкычы» (2002), «Алыплар илендә» (2002), «Нух пәйгамбәр көймәсе» (2004), «Туфаннан таралган татарлар» (2004). Вәсилә апалары аларга мәктәптә бу китаплар турында сөйләгән инде, алардан өзекләр укыганнар, шуңа күрә дәресләр җиңел үтте. Әгерҗе якын булгач, авылда катнаш никахлар да шактый икән, җәйге җәйләүгә йөрүчеләр арасында да андый гаиләләрдән балалар бар иде. Әмма без татарча аралаштык, бик сирәк очракларда гына, сорауларга русча да җавап бирергә туры килде.

Вәсилә Хәкимова исә балаларга гарәп теле буенча башлангыч мәгълүматлар бирде, аның әлифбасын өйрәтте. Ни гаҗәп, балалар өчен иң кызыклы дәрес шушы булгандыр, мөгаен! Һәр хәрефне язарга өйрәнгән саен, шатланалар! Тактага чыгып, гарәп хәрефләре белән үз исемнәрен язу алар өчен зур җиңү иде! Югыйсә, Иж-Бубый музейларында сакланган бөтен борынгы мирас – шушы гарәп хәрефләре белән бит, ә авылда аларны укый алучылар юк дәрәҗәсендә. Мәктәптә дә гарәп хәрефләрен өйрәтергә рөхсәт юк икән, хәтта факультатив та! Югыйсә, Вәсилә Хәкимова аларга бер кышта гарәп әлифбасында укырга-язарга өйрәтер иде, әмма рөхсәт ителми...

Безнең төп хыялыбыз – Иж-Бубый авылында яңадан мәдрәсә ачу, чөнки бу авыл тарихка бары тик мәдрәсәсе белән генә кереп калды, шундагы дога-гыйбадәтләр хисабына яшәде. Иж-Бубыйда хәзер дин юк дәрәҗәсендә, гадәти көннәрдә хәтта мәчеткә намазга йөрүчеләр дә юк, җомга көн 3-4 ират... Җитмәсә, авыл урыслашып та бара, мәктәптә дә төп предметлар русча укытыла, катнаш никахлар шактый. Бу авылны бары тик ислам гыйлеме һәм әхлагы гына коткарып калачак, ә аның нигезе – мәдрәсәләрдә. Иж-Бубыйда мәдрәсә ачу өчен бина да бар, ул – 1895 елда төзелгән, хәзер буш торган мәчет бинасы. Дөрес, авылда, элеккеге кебек, кыз балалар өчен гимназия ачарга хыялланучылар да бар. Әмма ул уку йорты дөньяви (светский) булса, анда, Иж-Бубый мәктәбендәге кебек, дингә урын булмаячак...

Дәрестән бушаган араларда Иж-Бубый музейларында да булдым. Анда әле аны оештыручы Рәмзия ханым Хәлиуллина исән чакларда ук булганым бар иде, фәнни конференция вакытларында да анда кермичә китмәдем. Хәзер музей белән Алсу Хисмәтуллина җитәкчелек итә, ул үз эшенең зур белгече, интеллектуаль яктан әзерлекле, эзләнүчән шәхес. Бер бүлмәле мәктәп музеенда авыл тарихы да, мәдрәсә, Бубилар тарихы да киң яктыртылган. Экспонатларның күп өлеше авыл тарихы музеена тапшырылса да, узганнарны бер ноктада күз алдына китерерлек панорама булдырылган.

Бу нисбәттән авыл тарихы музееның хәле яхшырак, аның мәйданы да, мөмкинлекләре дә чагыштыргысыз, ул ике катлы таш бинага урнашкан. Минем әле Татарстанда, бигрәк тә авылда, мондый затлы музей күргәнем юк иде! Әлбәттә, музейның түрендә, үзәгендә Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә Буби-Нигъмәтуллиннар. Аларның бай мирасы, язган китаплары, сирәк тарихи фотолар, кулланган әйберләре биредә саклана. Музейда данлыклы Иж- Бубый мәдрәсәсе тарихына

төбәге

● Иж-Бубыйдагы мәчет.

да зур урын бирелгән, шул ук вакытта, авыл, төбәк, милләт тарихы да чагылыш тапкан. Музей фәнни юнәлештә дә эзләнүләр алып бара, Нигъмәтуллин- Бубилар нәселе буенча өр- яңа мәгълүматлары бар.

Иж-Бубыйның авыл тарихы музее – аның мөдире Раиф әфәнде Гәрәевнең гомерлек хезмәте нәтиҗәсе. Аның дәвамчысы да бар, кызы Нурия Мәннапова музейда фәнни хезмәткәр булып эшли, тарихи эзләнүләр алып бара. Аталы-кызлы бу замана мәгърифәтчеләре - Бубилар башлаган изге эшне дә дәвам итүчеләр.

Әмма авыл тарихы музееn милләт өчен тагын да файдалырак эшләтеп булыр, ул бу төбәктәге тарихи-мәдәни мирас үзәге бурычын үтәсен иде. Буби укуларын, фәнни-гамәли конференцияләрне, төбәк тарихына багышланган җыеннарны, шушы темага язылган китапларның презентацияләрен дә биредә уздырырга мөмкин. Әгерҗе төбәгеннән чыккан башка күренекле шәхесләр турында да мәгълүмат өстәлсен иде. Интернетта эшчәнлекне югарырак дәрәҗәгә күтәрү дә мөмкин, чөнки бу бай мирасны күрсәтә белүче белгечләр бар.

Иж-Бубый музейларында булганда, үзем өчен бер яңалык та ачтым, ул – атаклы Бубилар нәсел дәвамчысы Мәрьям Бубинская-Атмаҗаның язмышы. Моңа кадәр бу ханым Бубилар династиясе вәкилләре арасында юк иде, ә ул мәгърифәтче Гобәйдулла Буби-Нигъмәтуллинның беренче никахыннан туган кыз булып чыкты, Атмаҗа фамилиясе исә төрек иренеке. Төркия өчен Мәрьям Атмаҗа – каһарман хатын, милли герой. Аның тиңсез батырлыгы, фидакарьлеге – Беренче бөтендөнья сугышы вакытында урысларга әсир төшкән төрек гаскәриләрен коткаруда. Мәрьям Бубинская 1800 әсир төрек офицер һәм солдатын, үз кесәсеннән 10 мең алтын акча түләп (хәзерге 1 миллион Америка доллары), ирекккә чыгара, алар арасында аның булачак ире Али Рыза да була.

Дөрес, бу хәлләр инде совет власте урнашкач була, Мәрьям ире Али һәм әсирлектән азат ителгән төрекләр белән әле Төркестанда, большевикларга каршы сугышларда да катнаша, анда кызыл гаскәрдән җиңелгәч, алар Әфганстан, Иран аша, бик авырлык белән, Төркиягә кайтып җитә. Ире Али биредә Төркия хәрби көчләренә хезмәткә керә, зур дәрәҗәләргә ирешә. Мәрьям Бубинскаяның төгәл үлү елы хәзергә билгесез, галим Айдар Хәйретдиновның язуы буенча, бу хәл 1945-1946 елларда булырга мөмкин. (Айдар Хәйретдинов. Мәрьям ханым: Бубилар нәселенең онытылган каһарманы // Историческая этнология. 2022. Том 7, № 1, 94 б.)

Ассызыклап үтик, Мәрьям Бубинская-Нигъмәтуллинаны милләтебезгә кайтаручы галим – Айдар Хәйретдинов, ул аның хакында Төркия матбугаты аша өйрәнеп, күп мәгълүмат тапкан. Хәзер бу эшне музей хезмәткәрләре Алсу Хисмәтуллина һәм Нурия Мәннапова дәвам итә. Нурия ханым интернет аша Мәрьям Атмаҗа турында күп яңа мәгълүмат тапкан, бу каһарман татар хатыны турында Төркиядә хәтта документаль фильм дә төшергәннәр, бәлки әле нәфис фильм дә туар. Тик Төркиядә аны каһарман төрек ханымы, дип язалар. Бик сирәкләре генә Мәрьям Атмаҗаның татар икәнлеген искә ала, әмма Уфа белән бутыйлар. Хәзер боларның барысына да ачыклык кертергә кирәк булачак. Иж-Бубыйның авыл тарихы музеенда Мәрьям Бубинскаяның бер почмагы да булдырылган, биредә аның турында өстәмә материаллар туплау дәвам итә.

Шөкер, Әгерҗе төбәгендә Мөхлисә һәм Мәрьям Бубиларның эшләрен дәвам итүче фидакарь татар хатын-кызлары бар. Иж-Бубыйда алар Вәсилә Хәкимова, Алсу Хисмәтулина һәм Нурия Мәннапова булса, районның Биектау авылында исә мин башка мәгърифәтче ханымнарны да очраттым. Эльза Сибгатова «Бөек Себер юлында Биектау» дип аталган әдәби-документаль җыентык бастырган, ә Нурания Көбәш (Төхбәтуллина) әдәби жанрда повестьлар һәм хикәяләр иҗат итә. Алар икесе дә шушы Биектау авылыннан, гомер буе укытучы булып эшләгәннәр, әмма Эльза ханым Мордывый авылында, Нурания Көбәш районның иң читендә булган Кадыбаш авылында яшиләр.

Шунысы гаҗәп, Нурания ханым дөньяның иң читендә яшәгән кебек тоелса да, язган әсәрләре белән халыкара бәйгеләрдә катнаша һәм дөньякүләм җиңүләр яулый. 2021 елда ул үзенең «Сөйли, җырлый, сагына торган материя» дип аталган хикәясе белән «Ачык Евразия» дип аталган, Лондонда уздырылган халыкара бәйгедә финалга чыга. Аңа кадәр исә, 2016 елда, Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара төрки бәйгедә Татарстан буенча икенче урынны ала. Мин Нурания Көбәшнең 2008 елда Казанда басылган «Мутантлар» китабын укып чыктым, автор тормышны да, кеше күңелен дә яхшы белә, ул дөньяга фәлсәфи-психологик күзлектән карый һәм бәя бирә. Тасвирлавында нечкә юмор һәм ачы хакыйкать аралашып бара, урыны-урыны белән бу әдәби алым символик трагикомедия дәрәҗәсенә ирешә, шул ук вакытта әсәрләрендә ашыгып сөйләнгән натуралистик урыннары да бар. Нурания ханымга темасын киңәйтсә, шушы төбәктә яшәгән тарихи шәхесләр, хатын-кыз каһарманнар турында язса, әйбәт булыр иде.

Биектау авылы турында китап язган Эльза ханым Сибгатова исә документаль жанрда эшли, эзләнүләр алып бара. Аны узган кыш очрашулар вакытында да, быел Болгар халыкара форумында да очраттым, ул авылдашы, тел галиме, профессор Мөхетдин Корбангалиев турында чыгыш ясады. Быел ул мөхтәрәм галимнең, милләтне гарәп-латин-кирилл имляларында әлифбалы итүче шәхеснең туууна 150 ел икән, Эльза Сибгатова шуны зурлап билгеләп уздырырга әзерләнә. Әлбәттә, бу истәлекле датаны галимнең туган авылы Биектауда да, Иж-Бубыйның авыл тарихы музеенда да, Казанда да олылап билгеләп үтәргә кирәк. Эльза Сибгатованың «Бөек Себер юлында Биектау» китабында Мөхетдин Хафизитдин улы Корбангалиев (1873-1941) турында күп кенә кызыклы һәм бай мәгълүмат бирелгән. Баксаң, аның атасы алпавыт Тәфкилевның крепостной крестьяны булган икән. Әйе, Биектау авылы, тирә-юньдәге берничә татар авылы кебек, коллыкка сатылган татарлар авылы була. Биектау халкы башта алпавыт Каныш Яушевның крепостной коллары санала, аннан ул аларны Тәфкилевка сата...

Менә шул кол татарлар арасыннан Мөхетдин Корбангалиев кебек акыл ияләренең чыгуы авылның элек-электән дини, мәгърифәтле булуыннан килә. Биектау бик борынгы тарихлы, мәчет-мәдрәсәле авыл булган. Ә 1885 елда монда хәтта дәүләт тарафыннан рус-татар мәктәбе дә ачыла, анда танылган тарихчы Гайнетдин Әхмәрев авыл балаларына рус теле укыта. Мөхетдиннең зиһенле бала икәнен аңлап, ул аңа Казанга, татар укытучылар мәктәбенә барырга киңәш итә. М.Корбангалиев Казандагы бу уку йортын уңышлы тәмамлый, укыганда ук, К.Насыйри, Радлов кебек мәгърифәтчеләр белән таныша, алар киңәше белән, фән юлына кереп китә, 1917 елга кадәр авылларда һәм Казанда балалар укыта һәм дәреслекләр яза башлый. Бүгенге көндә педагог, тел белгече Мөхетдин Корбангалиевның йөздән артык фәнни хезмәте билгеле, ул татар, рус, география, математика буенча дәреслекләр, шулай ук программалар, сүзлекләр, укыту кулланмалары авторы, латин һәм кирилл хәрефләрендәге «Әлифба»ның атасы, Казан дәүләт университетында татар теле кафедрасына нигез салучы, 11 тел белгән профессор... Бу танылган шәхеснең репрессияләргә эләкмәвенә бәлки аның крепостной баласы булуы сәбәпчедер. Шәхес культы елларында юк ителгән татар мәгърифәтчеләре эшен аңа дәвам итәргә туры килә. Мөхетдин Корбангалиев 1941 елның 3 июнендә, сугыш башланырга берничә көн кала, йөрәге ярылып үлә...

Менә шундый авыл ул – милләткә акыл ияләре биргән, крепостной татар коллары авылы Биектау. Мин аны бик яратып өйрәндем, халкы белән аралаштым. Бу авылда биек таулар юк, исеме, галимнәр язганча, Биктәү дигән татар кешесе исеме белән бәйле булырга мөмкин, русча да ул тәрҗемә ителмичә, Биктово, дип кенә язылa. Таулары булмаса да, авылда Әби патша күпере, дип аталган таш күпер саклана, аның аша кул-аяклары богаулы каторжаннарны этап белән Себергә сөргәннәр, авыл башындагы урманда аларның туктап төн куна торган алачыклары да булган. Биектау аша Пугач яулары да узган, авыл ирләре дә анда катнашкан, соңыннан аларның күбесе рәхимсез рәвештә җәзалап үтерелгән. Эльза Сибгатова китабында боларның барысы турында да мәгълүмат бар.

Әгерҗе төбәге турында күпме язсаң да, язып бетерә торган түгел, чөнки бу тарих әле өйрәнелә генә башлады. Мең елдан артык шушы җирләрдә көн күргән, тамырларында «Арские князья» дип аталган затлы һәм гайрәтле нократ татарларының канны аккан, тарихи болгар-ногай-татарларның рухи дәвамчылары булган халык яши монда! Бу яклардан да көчләп чукындыру гарасаты шаулап үткән, ул тема әле аз өйрәнелгән. Бу төбәктә татар алпавытлары Яушев һәм Тәфкилевлар да, милли мәгърифәтчеләр Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә Нигъмәтуллиннар, Мөхетдин Корбангалиевлар да яшәгән. Тарихы һәм язмышы белән кырыс та, сагышлы да төбәк бу – Әгерҗе яклары, күпләребез өчен әле ачылмаган тарих, язылмаган китап!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Мәдәни җомга
4 август
№30, 2023

Яшәргә язса...

Бар дөнья халкы 6 һәм 9 августта Хиросима һәм Нагасаки фаҗигасын искә алганда, японнар бу кешене дә һәрчак истә тота. Аның кебек, ике атом бомбардировкасыннан соң да исән калган японнар саны – 164. Әмма бу фактны рәсми рәвештә раслаган бердәнбер япон кешесе – ул гына. Цутому Ямагути.

Нагасакида 1916 елның 16 мартында туган Цутому Ямагути яшьлегендә бик тә уңган кеше була. Ләкин бу аяныч вакыйгалардан соң аны кемнәрдер иң бәхетсез кешеләр рәтенә, ә кемнәрдер, киресенчә, аны иң бәхетлеләр рәтенә кертә.

Сугыш вакытында Ц.Ямагути Император армиясе сафларында булмый. Сугышта катнашмый. Чөнки ул «Мицубиси» компаниясенең бик алдынгы инженеры булып санала. Аның инде хәләл җефете дә бар, улы да туган була. 1945 елның августында әлеге уңган-булган 29 яшьлек хезмәткәрне нефть танкерын төзүдә катнашу өчен, Хиросимага командировкага җибәрәләр. 6 августта ул заводка бик яхшы кәефтә килә. Ни дисәң дә, бу – командировкасының соңгы көне бит! Тиздән ул яраткан гаиләсе белән күрешәчәк! Әле бүләкләр дә алырга да җитешәсе бар!

Әмма беренче атом бомбасы шартлагач, бары да мизгел эчендә үзгәрә. Бу вакыт ул судно төзү урынында була. Корылма эченнән урамга чыга. Цутоми күктәге АКШ бомбардировщигын күреп ала, әмма аның хакында бу бер разведчик-очкычтыр, дип уйлый. Андый очкычлар, гадәттә, япон күгендә еш күренә. Шул мизгелдә үк һавага якты нурланыш тарала. (576 метр биеклектә атом бомбасы шартлый.) Аннан соң тирә-юньгә гаять дәрәҗәдәге, буып ала торган эсселек тарала. Завод та дулкын тәэсирендә шундук җимерелеп төшә, андагы кешеләр дә кырылып бетә.

Әйе, 1945 елның 6 август иртәсендә экипаж командиры энисе хөрмәтенә «Enola Gay» дип аталган америка бомбардировщигы B-29 Хиросимага 13-18 килотонна тротилллы атом бомбасын ташлый. Ул Айой күпере кырында, авыр чирләрдән дәваланучы балалар яткан Сима госпиталеннән 600 метр ераклыкта шартлый. Атака вакыты алдыннан бу кала халкы 245 мең кеше булып исәпләнә. Очкычлар якынлашуын хәбәр иткән радарлар челтәре нәтиҗәсен исәпкә алып, башта һава тревогасын игълан итәләр. Әмма иртәнге сәгать 8 дә әлеге тревога кире алына, һәм радио буенча очкычлар разведкасы булу куркынычы аркасында бомбадан саклый торган урыннарга юнәлергә генә киңәш итеlә. Күп кенә туктап калган сәгатьләр шундый вакытны күрсәтә – 8 сәгать 15 минут. Шартлау эпицентрыннан 800 һәм аннан да азрак метр якынлыктагы кешеләрнең 90 проценты берничә минут эчендә үлә. Шәһәрдә янгын чыгып, утлы давыл барлыкка килә. 80 мең кеше һәлак була. Беренче рәсми хәбәр атом бомбасы шартлап, 16 сәгать үтүгә Вашингтоннан киләчәк, һәм японнар ни булганына шул чакта гына төшенә башлаячак.

Ә фаҗига мәлендә әлеге ир-ат бәхетенә, кырыйда чокыр булып, ул бик тиз арада шул чокырга сикерә ала. Ләкин шартлау дулкыны шундук аңа кадәр килеп җитә һәм ир-атны ун метрдан ары тотып ата. Ул шушы коточкыч халәтне кичеп тә исән кала.

Исән калган кешеләргә карата Японияда «хибакуся» дигән махсус термин куллана башлый. Ц.Ямагути – шуларның берсе. (Гомумән, хибакусяга шартлау эпицентрыннан берничә километр ераклыкта булучыларны, шартлаудан соң ике атна дәвамында эпицентрдан ике километрдан да арырак булмаучыларны, радиоактив төшемнәргә эләгүчеләрне һәм энилэре шушындый халәтләргә эләгеп, алардан туган балаларны гына кертәләр. Әмма мондый авырулар инде эшкә урнашуда да кыенлыкка юлыга, чөнки радиация ул йогышлы икән дип уйлаучылар да күп була, алар белән гаилә корырга телүчеләр дә табылмый, чөнки гарип балалар туу очраклары хакында да уйланалар).

Исән калгач, Ямагути үз күзләренә үзе ышанмый. Чөнки Җирдә төн туа. Шартлау аркасында гаять күп тузан һәм көл оча. Ул яраланганга күрә көч-хәл белән генә атлый. Зур авырлык белән үзенең ике коллегасын эзләп таба. Алар бергәләшеп, бомбалардан саклану урынына кадәр барып җитә һәм биредә аларга беренчел медицина ярдәме күрсәтелә. Тирә-юнь тәннәре пешкән кешеләр белән тула... Алар да бер-бер артлы үлә бара. Ә инде эпицентрга якынрак булганнарның тәннәре кара күмергә әйләнә. Очып барган кошлар һавада янып бетә, коры кәгазь эпицентрдан ике километр ераклыкта дөрләп яна. Дулкын көче кешеләрне аяктан ега, нурланыш кеше тәненә киемендәге рәсемнәрне көйдереп суга. Диварларда кеше сурәтләре кала. Иң нык биналар гына җимерелми. Үлүчеләрнең күбесе сугышта катнашырга чакырылган кореялылар булуы хакында да мәгълүматлар бар. Тиздән кара яңгыр башлана. Радиактив яңгыр кара, сыланучан су халәтендә җиргә сеңә. Белгечләр әйтүенчә, нурланыш зыяны алган кешеләр аек акылда була алмый. Алар үзләреннән алда баручы кешегә ияреләр. Берни ишетмиләр һәм берни тоймыйлар. Әйтерсең, алар нидер белән чорнап куелган. Шартлаудан соң тәннәреннән кан аккан күпләр торып баса һәм шеренгаларга тезелеп, әкрен генә алга таба атлап китә. Бу зомбилар хәрәкәтен хәтерләтә. Аларның күбесе пешкән, күмерләнә башлаган кулларын алга таба сузып атлый, чөнки кулларын төшерә башласалар, каты авырту хисен кичерәләр. Алар елгага җитеп, суга кереп үлә. Моны күргән японнар бу хакта озак еллар буе сөйлиячәк...

Японияда, гомумән, бу фаҗиганың коточкыч тәэсирен соңлап аңлыйлар. Беренче көннәрдә нурланыш чире турында да, радиоактив зарар турында да кешеләр белми дә әле. Берничә көн буе ач, акылдан язар дәрәҗәдәге халык инфекциядән, пешүдән, кан агудан тилмереп, әкрен генә үлә бара. Бер мизгелдә көл булганнар белән чагыштырганда, боларның газабы чагыштыргысыз дәрәҗәдә күбрәк була. Булышлык күрсәтелми, чөнки госпитальләр юкка чыккан. Япон хөкүмәте барын да аңлап бетерми. Бар яралыларның су эчәсе килә. Алар бер йотым су сорый, әмма су булмый. Исән калганнар соңрак үзләрен гаепле итеп сизә башлый, аларга башкаларга ярдәм итерлек көчләре булган кебек тоела. Әмма аларның шулкадәр яшиселәре килә ки, хәтта җимерекләр астында калганнарның үзләрен чакыруларына да, ыңгырашуларына да игътибарсыз булалар.

Өч коллега тәрәзәләрендә пыялалары булмаган поездга утырып, янгын исе тулы Хиросимадан Нагасакига кайтырга чыга. Японнар эпицентрдан ике чакрым ераклыктан үтә. Радиация зарары тия. Күп пассажирлар елый. Ямагути янында утыручы ханым яңа туган баласы белән мәш килә, аны иске одеялга төрә. Нидер сөйли, әмма контузия алу сәбәпле ул аны ишетми дә. Тирә-юньне дә бераз гына күрә. Күз кырые белән ханымның нарасыена карый, әмма бу хатын-кыз күмерләнеп беткән нәрсәдер тоткан, үзе бертуктаусыз нидер сөйли. Ямагути игътибарын үз кулларына юнәлтә. Куллары бик нык пешкән. «Әйе, бу коточкыч йокы», дип уйлый ул. Уйлар да тупланмый, тиздән ул уяныр... Ул бит әле күптән түгел генә нефть танкеры сызымнарын сыза иде.

Әлеге поезд пассажирларын күргәч тә Нагасаки халкының коты оча. Калага кайтып җиткәч үк Ц.Ямагути шифаханәгә мөрәҗәгать итә. Чөнки аның ярты тәне пешкән, кул чуклары җитди зарарланган, колакларыннан һәм борыныннан кан ага, ә күзләре күрми диярлек. Аны хәтта бу шифаханәдә табиб булып эшләүче классташы да танымый. Шифаханәдә калырга бик нык кыстасалар да, ул гаиләсе янына ашыга. Кайтса, үз энисе үз улын танымый... Энисе баштан алып аякларына кадәр бинтлар белән уралып беткән улына карап: «Менә улымның өрәге кайткан», дип уйлый.

9 августта ук, тәненең күп урыны пешкән һәм тәнендә имгәнүләр булуына да карамастан, каты тәртипкә күнеккән әлеге япон ир-аты эшкә чыга. Офиста ул җитәкчесенә Хиросимада нәрсә булуы турында сөйли башлый. Ә җитәкче аның сөйләгәннәренә ышанмый. «Ничек инде бары тик бер бомба шундый да зур шәһәргә шулкадәр зыян салсын да, шәһәр булып шәһәр җимерелеп тә бетсен?!» – ди җитәкче. Шулчак тырыш хезмәткәр тәрәзәгә күз ташлый. Күктә тагын яктылык... һәм бу яктылык та Кояшны каплый. Офис та коточкыч яктылык белән тула һәм ул: «Хиросима болыты минем артымнан ияреп йөри, ахры», дип уйлый. Бу юлы да эпицентр әллә ни ерак түгел. Ямагути бәхетенә, дулкын аны зур булмаган бер ябык җиргә тотып ора. Янә шартлау урынының нибары өч километр ераклыкта булып чыга ул. Һәм тагын исән кала. Бу юлы авыр җәрәхәтләр дә алмый. Чөнки атом дулкыны аның эш урыны районына таучыклар аша зәгыйфьрәк булып килеп ирешә...

Шартлау нәтиҗәсендә 74-80 мең кеше һәлак була... Япон хөкүмәтенең премьер-министры Кантаро Судзуки һәм Чит ил эшләре министры Того Сигэнори шок халәтен кичереп, сугыш планнарыннан ваз кичә. 1945 елның 15 августында Япония императоры Япония капитуляциясе хакында хәбәр итә. Капитуляция өчен атом бомбалары кулланышы һәм моны аклау бүгенгә кадәр бәхәсләр куптара... Әмма 1945 ел ахырында инде Хиросимада яман чирдән һәм нурланыш авыруыннан үлүчеләр саны 90 меңннән алып 166 меңгә кадәр җитә, ә Нагасакида – 60 меңнән алып 80 меңгә кадәр кеше үлә. Радиация белән агуланыны ничек дәваларга кирәклеген төшенмиләр дә. Исән калганнар нурланыш авыруыннан җәфа чигә. Табиблар косу һәм эч китүләрне дизентерия белән бутый. Хиросимада яман шештән үлүчеләр саны 2 меңгә тула. Күпләр үз туганнарының үлемен үз күзләре белән күреп, психологик җәрәхәт ала. Өстәвенә, ул чакта радиоактив зарарлану дигән төшенчә дә булмый һәм исән калучылар үзләре яшәгән җирдә үк төпләнә дә башлый.

Ямагути да үзенең исән калуын могҗиза дип кабул иткәндер, мөгаен. Ә инде икенче могҗизага ул ярымҗимерек шәһәр буенча өенә йөгереп кайткач ышана. Йорт җимерек диярлек. Хатыны да, улы да исән! Алар аның өчен даруханәгә дару алырга дип чыгып киткән булган. Шартлау вакытында җир асты туннелендә калганнар. Әлбәттә, моннан соңрак гаиләдәге һәрберсе радиоактив нурланыш зыянын үзендә тоя. Аның хатыны да радиоактив төшемнәргә эләгә ич. Ләкин алар исән! Җир астында ятмыйлар. Бернигә дә карамыйча, бу гаиләдә әле тагын ике кыз бала да туа. Ц.Ямагути өчен дә үзенә карата берни игътибар кирәкми. Ул – Нагасакида исән калганнар статусында. Әмма Хиросимадагы атом бомбасы фаҗигасен кичереп тә исән калуы хакында бәхет иясе сөйләми. Чөнки исән калган дистәләрчә мең японнар да алдагы елларда үлә бит әле.

Әлеге японның чәчләре бик сирәкләнә, тешләре төшә. Исән кала алган 260 мең япон кешесе кебек үк, ул да каты авырулардан иза чигә. Ләкин дәваланулар да булышмый калмый. Тернәкләнеп, җирле портта кораб инженеры булып эшли. «Әтиемнең ике бомбага тотудан соң исән калуын күз алдына китереп булмый иде, ул яхшы кыяфәттә булды бит. Үзе дә үзен яхшы хис итүе хакында еш әйтә иде», – дип искә ала аның кызы.

Ул бары тик 2009 елны гына Хиросима фаҗигасендә дә исән калуы хакында рәсми рәвештә кәгазь бирүләрен үтенә һәм бу вакыйга, япон хөкүмәте карары белән, 2009 елда ук рәсми рәвештә раслана. Әйе, ул – ике атом бомбардировкасыннан соң да исән кала алган бердәнбер кеше.

Яңадан төзелгән Нагасакида, кызы Тошико тәрбиясендә яшәгән әлеге японны, гомере ахырында, Җир шарында атом коралы арту проблемасы борчый. Ул үз хатирәләрен туплый һәм китап нәшер итә. Документаль фильмда төшеп, үз күргәннәрен сөйли. Фильм Нью-Йоркта да күрсәтелә. Үсеп килүче буыннар бу фаҗигаләрне онытмасын өчен, мәктәпләрдә бик күп мәртәбәләр чыгыш ясый. 2006 елны Берләшкән Милләтләр Оешмасында да чыгыш ясарга насыйп була аңа. Күпләр аннан ничек итеп исән калуы хакында сораша, әмма ул аларга: «Мин белмим инде», дип кенә җавап бирә. Әлеге шәхес 2010 елның 4 гыйнварында, 93 яшендә, Нагасакида яман чирдән вафат була.

АКШта аның хакындагы бер телевизион тапшыруда алып баручы шаяртулар кушып сөйли һәм бу гамәле белән японнарны чыгырыннан чыгара. Ямагутиның кызы Тошико бу нисбәттән япон телевидениесе тапшыруында катнаша. Ул унике яшенә кадәр этисен бинтлар белән бәйләнгән килеш, чәчсез генә күргән бит. «Бу очрак 210 мең кеше тормышын юкка чыгарган атом бомбасы афәтен ахыргача аңламаганлыкны күрсәтә!» – дип нәфрәтләнә ул. Бу японның улы Катсутоши 2005 елны, 59 яшендә, яман чирдән дөнья куя. Кызы Наоко да сәламәтлеге аркасында, тумыштан зәгыйфь була. Әниләре дә 88 яшендә, яман чирдән вафат була.

Цутому Ямагутиның фамилиясе кодрәтле дип тәрҗемә ителүен дә искә алып, японнар аның сәламәтлеге артык какшамавына соклана. Әмма, бу нисбәттән, әлеге японның фәрештәләре күп булып, Аллаһы Тәгаләнең Кодрәте, Мәрхәмәте, Аның әмере белән исән калуын да онытмаска кирәктер. Аның гомере нәкъ шуның белән бәйле бит. Табигать тә Аның Кодрәте белән тернәкләнә. Янып көйгән җирләрдә 75 ел буе бернинди үсемлек тә һәм агач та үсмәячәк дип раслаган Манхэттен проектында катнашучы Гарольд Джейкобсон да шапырынуыннан туктый. Инде 1946 елның язында ук эпицентрдан ике чакрым ераклыкта гына урнашып та, исән калган агачлар, «Хибаку Юмоку» яшелләнә. Беренче булып олеандр үсеп чыга, чәчәк ата. Ике тал... Берсе апокалипсистан – 370 метр, икенчесе – 450 метр ары гына була. Аннары, авыруларга бирешмәүче гинкго билоба агачлары. Хиросимада 32 төрдәге 170 агач исән кала. Хиросима хакимияте мондый агачларның орлыкларын бар дөнья илләренә бүләк итә. Алар безнең илдә дә бар.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Тормыш – имтихан, сыналу ул

Әһәмиятле гамәл

Җирдәге тормыш – һәрберебез өчен сынау, ныклыкка тикшерү дөньясы. Башта – мәктәптә, аннан – техникумда һәм соңыннан институтта гыйлемне ни дәрәҗәдә үзләштерүебезне ачыклау, теге яки бу һөнәргә тиешле хәзерлекне алганыбызны раслау өчен имтихан бирәбез. Уку чорында меңләгән контроль һәм курс эшләре язабыз. Тиешле белгечлек алып эшкә урнашкач, башта әле ике-өч айлык сынау аша үтәсең. «Сынау срогы» уңышлы тәмамлангач та әле хезмәткәрне мең төрле тикшерү көтә: коллективта үз-үзен ничек тота, клиентлар белән ничек аралаша... Бу сынау-тикшерүләр хакында, хәтта, хезмәткәр үзе белмәскә дә мөмкин. Үз тиңеңне очратып, гаилә корырга ниятләгәч тә әле сынау үтәргә кирәк була – өйләнешер алдыннан кияү яки кәләшне, берәр көтелмәгән хәл китереп чыгарып, ике якның да әти-әнисе тикшереп карарга мөмкин. Әйе, имтихан алу, тикшереп карау, сынаулар үткәрү – ул тормыш зарурияте, башка кешеләрне аңлау өчен әһәмиятле гамәл.

Төрле хәвефләр аша

Уйлап карасак, бу дөньяга һәммәбез Аллаһы тәгалә тарафыннан сыналу өчен килгәнбез. «Ул, гамәлегезгә күрә, кайсыгыз күркәмрәк булганны сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яралтты» («Мөлек» сүрәсе, 2 нче аять). Тормышыбыз гел уңай гына бармый, төрле яктан имтихан үтәбез. Байлык белән дә сыный Раббыбыз: кая тотар икән малын, хәерле гамәлләр кылып, мохтаҗларга ярдәм кулы сузып яшәрме, яки гел байлык туплап, азганнан-азып, башка сыймаслык гөнаһларга батармы икән, дип. Акчалы кешегә гөнаһ ишекләре тагын да киңрәк ачыла, ул хакта күбебез белә, шуңа күрә мисаллар китереп, ул гөнаһларга реклама ясап тормыйбыз. Байлык белән генә түгел, кеше әле фәкыйрьлек белән дә сынала. Очын-очка ялгый-ялгый яшәп, булганына шөкер итеп, канәгать була белерме, яки гел зарланып, көнләшеп, кешеләрне сүгеп гомер кичерерме, дип сыный Аллаһы тәгалә андыйларны. Ул әйтә: «Без сезне бераз төрле хәвефләргә салып, ачлык-кытлык хәлләрендә калдырып, мал-мөлкәтне югалтырып, үлем белән җаннарны сирәгәйтеп, бакча-басуларыгызны афәтләргә дучар иттереп, җимеш бирүләрен киметеп, шуның белән уңыш алуга зыян китереп, сынап торабыз – сабырлыгызны тикшерәбез. И, Мөхәммәд! Син сабыр булганнарны сөендер, кайгыларга дучар була торып: «Дөреслектә, без – Аллаһыныкы. Ул – безнең Хуҗабыз. Һәм, һичшиксез, үлгәннән соң без Аңа гына кайтабыз», – дип әйтүчеләрне шатландыр. Алар – Раббыларының мактауларына һәм рәхмәтенә ирешүчеләр. Алар – туры юлга күнүчеләр» («Бәкара» сүрәсе, 155-157нче аятьләр).

Үзебезгә бәйле

Сәламәт килеш йөгереп йөргән җирдән кисәк кенә авырып, урын өстенә ауган вакытларыбыз да була. Ә инде савыгып аякка баскач, Раббыбызга шөкер итеп, хәерле гамәлләр кылып, намазлар укып, уразалар тотып, тормышны яхшы якка үзгәртербезме; әллә элекке шикелле «гыйбадәткә вакытым юк» дип, төрле акланулар табып, бозык-фәхеш гамәлләргә кабат керешербезме – һәркайсыбызның үзенә бәйле. Аллаһы тарафыннан тикшерү үтәргә мөмкинбез. Аллаһы безгә тән бирде. Аңа гыйбадәт кылып, хәләл ризык белән генә тукланып тору фарыз булып, Кыямәт көнендә аның өчен дә җавап тотачакбыз. Раббыбыз биргән аяклар белән кайларга кердек, күңел ача торган гөнаһ оялярына йөрмәдекме? Кулларыбыз белән рөхсәт ителгән нәрсәләрне генә алдыкмы яки кешенекен урладыкмы?!

Туры юл

Башыбызга төшкән төрле сынаулар – авыр вакытта уйланып, ни өчен яшәгәнебезне аңлап, гафиллектән иманга килеп, туры юлга басу һәм, үзебезне бар итүче бердәнбер илаһыга – Аллаһы тәгаләгә генә гыйбадәт кыла башлау өчен дә бирелергә мөмкин. Гадәттә, табиблар да, һәркем дә ярдәм итә алмаслык чиккә җиткәч, үзе дә аңламастан, кеше кулларын өскә күтәреп ялвара, дога кыла башлый. Чөнки аның фитрасы Раббысына тартыла, ул үзенең көчсезлеген аңлый, бар нәрсәгә кодрәтле булган ниндидер Зат барлыгын аңы белән тоя. Кайбер кешеләр дингә дә авыр сынаулар аша үткәч кенә килә. Аларга сорау бирсәң, җаваплары гади: «Беркем дә ярдәм итә алмагач, кулымны күтәреп, елый-елый ялвардым һәм Раббым җавап бирде. Хәзер инде ничек Аңа табынмыйча, итагать итмичә, хәләлне харамнан аермыйча яши алыйм?! Ул гына хакыйкый ярдәм итүче, саклаучы».

Иманыбыз, ышанубыз ни дәрәҗәдә икәнен тикшерү өчен дә безгә сынаулар килергә мөмкин. Мондый имтихан вакытында чын иман әһеле белән икейөзлеләрнең хакыйкый йөзе ачыла да инде. «Әллә кешеләр иман китердек, дигәннәреннән соң төрле авырлыклар белән Аллаһы тарафыннан имтихан ителмәбез, дип уйлыйлармы? Болардан элек тә төрле сыйныф кешеләрен бәла-каза һәм авыр мәшәкатьләр белән сынап карадык, кемнең иманы хак һәм кемнеке ялган, шуны белмәк өчен Аллаһы мөселманнарны төрле авырлыкларга салды» («Ганкәбут» сүрәсе, 2-3нче аятьләр).

Төрле проблемларга юлыккач, шулардан тиешле нәтиҗә ясасак һәм тормышыбызны яхшы якка үзгәртү өчен иманга килергә тырышсак иде.

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

5 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 18нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 22.00 сәгатьтә калка, 9.25 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 15.49 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Холестеринны киметеп була

Көн саен 2 кишер ашау ярты елда холестерин микъдарын 10-20 процентка киметә ала. Көн саен 1 бүлем сарымсак ашау кандагы куркыныч холестерин күләмен ярты елда 44 процентка азайтырга мөмкин. Көн саен 1 грейпфрут ашау 8 атнада холестерин микъдарын 6 процентка төшерә, тик әлеге җимешне ач карынга һәм дару эчәр алдыннан ашарга ярамый.

6 август (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 19нчы көне. 21нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 22.08 сәгатьтә калка, 10.56 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 15.45 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Җитен мае

Калкансыман бизне ныгыту өчен, прополислы җитен мае эчү файдалы. Ярты литр җитен маена 3-4 аш кашыгы вакланган прополис (туңдыру камерасына куеп торсаң, ватарга җиңелрәк) кушып, әледән-әле болгатып, сүрән утта прополис эреп беткәнче тоталар. Капкачы яхшы ябыла торган савытта салкынча урында саклыйлар. Иртән һәм кичен ач карынга 1әр десерт кашыгы кабалар. Дәва курсы – 1 ай.

7 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 20нче көне. 22нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 22.17 сәгатьтә калка, 12.27 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 15.42 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Стенокардиядән – җимеш суы

Стенокардия (күкрәк бакасы) интектергәндә, 4әр аш кашыгы гөлҗимеш һәм дуләнә җимешләрен 2 литр кайнар суга салып, 2 көн төнәтәләр дә, марля аша сөзеп, ашаган саен 1әр стакан эчәләр. Дәва курсы – 2-3 атна.

8 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 21нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 22.29 сәгатьтә калка, 13.57 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 15.38 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Инсульттан соң

1 кг лимонны иттарткычтан чыгарып, шулкадәр үк шикәр кушалар, яхшылап болгатып, суыткычта пыяла банкада саклыйлар. Һәр иртәнә 1 бүлем сарымсак белән ашыйлар. Яисә икешәр лимон һәм әфлисунны иттарткычтан чыгарып, 2 аш кашыгы бал кушып болгаталар да, тәүлек буе бүлмә температурасында тоткач, суыткычта саклыйлар. Көненә 2-3 тапкыр 1-2 шәр аш кашыгы кабалар.

9 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 22нче көне. 24нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 22.29 сәгатьтә калка, 13.57 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 15.34 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

10 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 23нче көне. 25нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 23.08 сәгатьтә калка, 16.55 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 15.29 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Прополислы май

Прополис гөмбәчек, бактерия һәм вирусларны юк итә, һәм, антибиотиклардан аермалы буларак, аларның берсе дә аңа яраклаша алмый. Грипп, туберкулез, дифтерия китереп чыгаручы вирусларны җиңәргә сәләтле. Файдалы үзлекләрен әллә ничә ел саклый. 90 миллилитр чистартылмаган үсемлек маен 3-4 минут кайнатып, 80 градуска кадәр суыталар да, 10 грамм прополис өстәп, ул эреп беткәнче 15-20 минут болгаталар. 2 кат марля аша сөзеп, суыталар. Суыткычта 1 ай саклана. Мондый май яраларны бик шәп төзәтә, вагинит, кольпит, кандидозны дәвалый. Прополис маен эчкәндә исә ашказаны-эчәк тракты җәрәхәтләре тиз төзәлә, яман шеш күзәнәкләре үсүдән туктый, холестерин микъдары кими, иммунитет ныгый.

11 август (җомга). ***Мөхәррәм аеның 24нче көне. 26нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 23.44 сәгатьтә калка, 18.11 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 15.25 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Маринадланган кыяр

Кечкенә кыярларны (корнишон) 4 сәгатькә салкын суга салып куялар. 1 литрлы 4 банкага җитәрлек маринад әзерлиләр: 2 литр суга 7 аш кашыгы шикәр, 3 аш кашыгы тоз салып, кайнатып чыгаралар, сүндергәч, 180 мл 9 процентлы серкә өстиләр. Банкаларга дүрткә бүленгән 1әр кишер, бөрҗалап туралган 1 әр баш суган, 1-2 шәр укроп зонтигы, тыгызлап кыярларны тутыралар да, кайнап торган маринадны коеп, тимер капкач белән каплыйлар.

ХАҖ – бәгырьгә шифа

Аллаһ тәгаләнең зур бүләге буларак, былтыр мин фәкыйрегезгә дә хаҗ гыйбадәтен үтәү насыйп әйләде. Чын мәгънәдә зур бүләк, чөнки хаҗ сәфәрен 100 гә якын хаҗига республикабыз башлыгы бүләк итте.

Хаҗның гыйбадәтләре һәркемгә бертөрле булса да, йөрәктәге хис-кичерешләр үзгә, бу язмамда нәкъ шул турыда – хаҗның күңелгә ничек тәэсир итүен, нинди хис-кичерешләр уятуын сөйләргә булдым.



Безнең сәфәребез Мәдинә шәһәреннән башланды. Аэропортка килеп төшкәч, безне каршылаган автобуслар янына чыкканда, бөтен тәнне кайнар һава урап алды. Мондый эссегә өйрәнмәгәнлектән, күңелдә курку хисе барлыкка килде: «Ошбу эсселеккә ничек түзәрмен?». Кондиционерлы автобусларга кереп урнашкач, тынычландык, алда торган Мәдинәгә сәфәр турындагы уйлар күңелне биләде. Менә автобуслар кузгалды, безнең күзләр – тәрәзәдә. Пыяла артында комлы, ташлы җир сузылып ята. Бер җирдә агач юк, ком, таш, кырыс һава. Бераз барганнан соң, автобуслар туктады, кулларына кап-кап күчтәнәчләр күтәргән гарәп егетләре килеп керде. Безгә: «Хаҗыгыз кабул булсын», дип зәм-зәм сулары, ризык тараттылар. Мәдинәгә барып җиткәнче, безне берничә мәртәбә туктатып, шулай күчтәнәчләр өләштеләр. «Хаҗи – Аллаһының кунагы», дигән хәдис бар. Менә шулай самолеттан төшеп, әле әз генә ара үтүгә Аллаһы тәгалә безне сыйлый башлады.

Мәдинәгә җиткәч, кунакханәгә якынлашканда ерактан ук, Пәйгамбәребез мәчетен күреп алдык. Ул үзенең зәвыклыгы, матурлыгы белән сокландыра. Килгән көнне үк мәчеткә барып, Пәйгамбәребезгә сәлам бирдек (ул бу мәчеттә күмелгән), намазларны укыдык.

Икенче көнне безгә ир-атлар, хатын-кызлар аерым-аерым вакытларда Рауда бакчасына барасыз, диделәр. Пәйгамбәребез мәчетенең уртасында дөньядагы иң яхшы урын – «Рауда» бар, ул «Җәннәт бакчасы» дип тәрҗемә ителә. Аның турында сахих хәдистә хәбәр ителә: «Минем каберем һәм минбар арасына Рауда урнашкан, ул – җәннәт бакчаларының берсе» (Бохари, Мөслим). Пәйгамбәребез кабере янында булу барыбыз өчен дә бик дулкынландыра торган мизгел, шуңа без бу минутларны шатланып көтеп алдык. Чират зур, вакытыбыз җиткәч, Пәйгамбәребез янына без дә кердек. Пәйгамбәребезгә сәлам бирдек. Ике рәкәгать намаз укыдык. Улчак йөрәк сафлык, мәрхәмәтлелек хисләре белән тулды. Бу саф хисләр күңелдә еллар буе җыелган авырлыкны, үпкә-рәнҗешләрне эретеп, күз яшьләре итеп агыздь. Шактый еллар намазда булсам да, мондый күңел халәте тормышымда беренче мәртәбә булды. Шушындый рухи чисталыкны, рухи югарылык һәм матурлыкны тойдыргань өчен мин Раббыма чиксез рәхмәтле.

Өч көннән соң без Мәккәгә юнәлдек. Барганда юл буе тәлбия сүзләрен әйтеп бардык. Юл буе безне шулай ук күчтәнәчләр белән сыйладылар. Килгән көнне үк Гомрә кылу максаты белән әл-Хәрам мәчетенә юнәлдек. Мәчеткә уң аяк белән кердек, тиешле догасын укыдык. Безгә төркем җитәкчеләре: «Беренче мәртәбә Кәгъбә ташын күрүчнең догасы кабул була», – диде. Бу дулкынландыргыч мизгелләрне көтеп, Гомрә хаҗы тәвафы кылырга Кәгъбәтулла урнашкан урынга юнәлдек. Менә ул – безнең алда, Кәгъбәтулла! Һәркем дога белән Аллаһы тәгаләгә юнәлде....

Кәгъбәтулла сул якта калып, сәгать йөрешенә каршы 7 мәртәбә дога кыла-кыла, тәваф кылдык. Аннары «Мәкам Ибраһим» артында ике рәкәгать намаз укып, зәм-зәм суы эчтек. Тәваф кылганнан соң җилкәләрдән тонна кадәр авырлык төшеп киткән кебек булды. Җилкәдә, кулларда, гәүдәдә җиңеллек. Моны безгә җитәкчеләребез шулай аңлатты: «Еллар буе кеше тормышында булган гөнаһлар, авырлыклар, үпкә-рәнҗешләр, күз тиюләр җанга, тәнгә СД дискка язылган кебек, язылып бара. Тәваф кылганда Кара таш бу негативны сөртә, чистарта. Кешенең калебе яктыра, нурлана. Чын мәгънәсендә Аллаһы тәгаләнең хикмәте һәм кодрәте».

Тәваф кылганнан соң, Сәгый кылдык. 7 тапкыр дога кыла-кыла, Сафә һәм Мәрва таулары арасында йөрдек. Бу мизгелләрдәге ихласлыкны, йөрәкләрнең Аллаһы тәгаләгә ничек ялварганын аңлатып бетереп булмый. Сәгый кылганнан соң, күкрәкләр киңәеп, йөрәкләр йомшарып калды. Аяклар арсa да, күңелләр күтәренке, җанда рухи чисталык һәм сафлык хисләре.

7 июль – зөлхиҗә аеның сигезенче көнендә төп хаҗ башланды. Безне автобусларда Мина үзәненә палаткаларга алып киттеләр. Анда идәнгә җәелгән матраста йокладык, күп итеп тәлбия әйттек.

Икенче көнне Гарәфә тавына юнәлдек, өйлә намазыннан соң кояш баеганчыга кадәр дога кылдык. «Хаҗ ул – Гарәфә» дигәнне ишеткәнегез бардыр. Әйе, бу көнне үзебез, гаиләбез, туганнар, дуслар, күршеләребез, мөселман өммәте, җөмһүриятебез, Ватаныбыз өчен дога кылдык. Дога кылуны сораган якыннарыбызны да онытмадык. Кояш баеганнан соң, Мөздәлифәгә барып, җиргә ятып, ачык һавада төн чыктык. Йолдызлы күк астында изрәп йокладык. Өченче көнне Зур баганага 7 таш аттык, безнең өчен корбан чалдылар, Тәваф белән Сәгый кылдык. Бу көнне җәяү 18 чакрым үткәнбез, алар сизелмәде дә, Аллаһы тәгалә көч-куәт бирде. Аннан соңгы көндә Зур баганага, Урта баганага, Кечкенә баганага җидешәр таш аттык. Бу төнне дә Минада кундык. Бу көнне Зур хаҗны йомгаклап Мәккәгә кайттык. Калган көннәребез дә гыйбадәттә, дога кылып, тәваф кылып, әби-бабаларыбыз өчен Гомрә кылып үтте. Соңгы көнне саубуллашу тәвафы кылып, кайтыр юлга җыендык.

«Синең өчен нәрсә ул хаҗ», – дип сорасалар, «Хаҗ ул – чисталык, сафлык, рухи ләззәт, күтәренке күңел, Аллаһы тәгаләгә якынаю юлы», – дип җавап бирер идем. Аллаһы тәгалә кылган хаҗларыбызны, гыйбадәтләребезне кабул итсә иде...

Чулпан МӘХМҮТОВА,
Казан шәһәрендәге «Рауза» мәчете имамының укыту эшләре буенча ярдәмчесе.

Авыл кызы опера сәхнәсендә

Татарстанның атказанган (1989), халык (1995), Россия Федерациясенең атказанган (2011) артисткасы, Казан дәүләт консерваториясе укытучысы, профессор Клара Хәйретдиновага шушы көннәрдә 75 яшь тулды.

Яңалык түгел, узган гасырда укытучыларны, партия, совет хезмәткәрләрен авылдан авылга, мәктәптән мәктәпкә күчереп йөрткәннәр. Шуның аркасында балалары да төрле мәктәпләрдә белем алырга мәҗбүр булган. Клара Хәйретдиновага да ун еллык урта белемне сигез мәктәптә укып алырга туры килә.

Моннан ун ел элек фани дөньядан киткән әнисе Мөнһәр апа Зәбирова авыр тормыш юлы узган, язмышның ачысын да, төчесен дә татыган, батыр йөрәкле хатын була. Утызынчы елларда Өнсә авылында яшәүче әтисе Габдрахман абзыйның колхозга кермәгәне өчен «халык дошманы» дип, өй алларын, келәтләрен сүтеп алып чыгалар. Ишле гаиләсе белән ул үзе шикелле авылдан куылган кешеләр аерылып чыккан Кутыр дигән авылда яши башлый. Көчләп колхозга кертелгәннән соң ишле гаиләдә балаларны ачлы-туклы үстерергә туры килә аларга. Мөнһәр Дөбьяз мәктәбенә йөреп җиденче сыйныфны тәмамлаган елны сугыш башлана. Ирләре сугышка киткән хатыннар белән бергә үсмер кызларны да урман кисәргә, окоп казырга җибәрәләр. Мөнһәрне укытучысы Фатыйма Хәбибрахманова гына окопка җибәртми кала. Кыз тагын бер ел укып, сигезенче сыйныфны тәмамлый һәм авыл мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли башлый. Хезмәт хакы итеп аена бер кадак – 400 грамм атланмай, 9 кило паек оны бирелә аңа. Арча районының Колачы авылы мәктәбенә укытучы булып җибәрелгән кыз шунда Әкрам атлы егеткә кияүгә чыга. 1946 елда аның беренче баласы Риклам туа. Сугыштан соң ул читтән торып Казан педагогия училищесына укырга керә. Укып йөргәндә икенче баласын, Клараны таба. Дөбьяз райкомы педагог белеме алган Мөнһәрне Рәс авылындагы Вахитов исемендәге колхозга партком секретаре итеп җибәрә. Аннары «Правда», Ульянов исемендәге, «Урал», «Татарстан» колхозларында эшли Мөнһәр апа. Башлангыч мәктәпнең өч ярым сыйныфын Клара Өнсә мәктәбендә укый, дүртенченең икенче яртысын инде Рәстә укып бетерә. Аннары бишенче – алтынчы сыйныфларны – Дөбьязда, алтынчының икенче яртысын, гомумән, туган яктан читкә китеп, Кырымда, Евпатория каласында тәмамлый. Җиденчене, туган якка кайткач, Соловцово мәктәбендә, сигезне – әнисе эшләгән Зур Ключидә, тугызны Биектауда һәм унны Мәмдәлдә укып бетерә. Тугызынчы сыйныфтан соң әнисе янына Мәмдәлгә күчеп килгәч, биредә ул әле үзе белән яшьтәш Фәүзия Әхмәдиярова исемле кызның әнисе белән бергә фермада бозаулар карый. Әле аттестат алганнан соң да колхозда эшләвен дәвам итә. Бары тик көз җиткәч кенә, кызының укытучы булуын, педагогия институтына укырга керүен теләгән әнисенең сүзен тыңлап, Казанга укырга китә, пединститутка керә. Ләкин кыз кечкенәдән җырга гашыйк булып үсә. Дөбьязда укыганда ул дуслары белән Хәмзә Закиров атлы баянчы оештырган ансамбльдә җырлап йөри, авылларга барып концертлар да куялар. Укуда алдынгы булганы, җәмәгать эшләрендә активлыгы өчен Клараны Артекка ял итәргә җибәрергә тиеш булалар. Ләкин сәбәбен әйтеп тормыйча гына, җибәрми калалар. Бик авыр кичерә кыз бу эшне...

Әлбәттә, аның җырлау сәләте әнисеннән килә. Мөнһәр апа да бик матур итеп җырлый торган була. Әле пенсиягә чыккач та үзе яши торган Мүлмә авылы клубында оештырылган «Чишмә» ансамблендә җырлап йөри.

Клара институтта ельярым гына укый. Аны җыр, музыка үзенә тарта. Икенче курсның беренче яртысын тәмамлагач, ул Татар дәүләт филармониясендә Мәскәүгә эстрада остаханәсенә укырга җибәрү өчен сәләтле яшьләрне җыялар, дигән хәбәрне ишетә һәм Филармония җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов янына тыңланырга килә. Сайлап алу конкурсында катнаша. Зиннур Нурмөхәммәтов, Рәбига Сибгатуллина, Римма Ибраһимовалар белән бергә, Мәскәүгә, эстрада остаханәсенә укырга китә. Анда ул атакчы җырчы Георгий Виноградовта белем ала. «Клара, синдә академик тавыш, сиңа консерваториядә укырга кирәк», – ди аңа мөгаллим. Казанга әйләнеп кайткач, ул укытучысының сүзен тыңлап, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә. Биредә талантлы, бик күп җырчылар тәрбияләп чыгарган укытучы Валентина Андреевна Лазько классында укып, классик җырлау серләрен үзләштерә. Консерваториядән соң кабат филармониядә эшли башлый. 1980 елда аны Казан дәүләт опера театрына чакыралар. Ул заманда театрда озак еллар эшләгән һәм опера спектакльләрендә җырлаган көчле тавышлы җырчылар белән көндәшлек итәргә тиеш буласың. Әмма Клара Хәйретдиновага операларда төп рольләрне башкаруны ышанып тапшыралар. Ул беренче дебюты белән үк үзенә күрсәтелгән ышанычны тулысынча аклый – А.Бородинның «Князь Игорь» операсында Ярославна партиясен башкарып, зур уңыш казана.

Табигый темпераменты, сәхнәдә үзен кыю тотуы, тавышы өстендә иренмичә эшләве, һәм ниһаять, үзенә генә хас лирик-драматик сопрано тавышы аңа уңышлы сәхнә карьерасын булдыру мөмкинлеген бирә. Ул үз репертуарын тудыра. Ярославна («Князь Игорь»), Лиза («Пиковая Дама»), Купава («Снегурочка»), Тоска («Тоска»), Дездемона («Отелло»), Мюзетта («Богема») ... Клара Хәйретдинованың опера театры сәхнәсендә уңыш белән башкарган төп рольләре әле бу исемлек белән генә чикләнми. Ул егермедән артык опера спектаклендә катнашып, республикабызның күренекле опера җырчыларыннан берсе булып танылa.

Клара Хәйретдинова еш кына зур уңыш белән чит илләрдә үткән опера фестивальләрендә чыгыш ясый. Төркия башкаласы Әнкарада үткән халыкара фестивальдә (1992) Аида партиясен («Аида», Верди), Венециянең «Ла Фениче» театрында «Борис Годунов» операсында Шинкарка ролен башкарып зур уңышка ирешә. Ул «Князь Игор»да Ярославна партиясе белән ике тапкыр Чабаксарда үткән М.Д.Михайлов исемендәге опера фестивалендә катнаша. Венеция фестивалендә аның партнерлары булып Россиянең Зур театры солистлары Таращенко, Веденеев, Мария театрында – Ванеев, Вена операсы солисты Анатолий Кочерга чыгыш ясый. 1996 елда Төркиядә «Төрексой» үткәргән Халыкара опера фестивалендә җырлау К.Хәйретдинованың иҗат биографиясендә зур вакыйга булып тора.

Опера спектакльләреннән тыш, Клара Хәйретдинова аерым концертлар да бирә. Аларда ул опералардан арияләр белән бергә, композиторларның әсәрләрен, халык җырларын зур осталык белән башкара.

Әле театрда эшләгәндә үк К.Хәйретдинова Казан дәүләт консерваториясендә укытучы булып эшли башлый. 2006 елда ул опера сәхнәсеннән китеп, тулысынча педагоглык эше белән генә шөгыльләнүгә күчә. Бер үк вакытта Казан музыка училищесында да дәресләр алып бара. Аның шәкертләре Казанның гына түгел, бөтен Россиянең төрле театрларында җырлап, опера сәнгатен сөючеләрнең мәхәббәтен яулый. Алар арасында Санкт-Петербургның Мария театрында җырлаган Артур Исламов, Германиядә эшләп кайткан Илүсә Хуҗина, Волгоград операсында җырлаучы Роман Байлов, Владивосток театры солисты Айгөл Хисмәтуллиналар бар. Училищеда аннан дәресләр алып җырлау серләрен үзләштергән, Дөбьязда үскән әрмән егете Аршак Алтунян, Теләче кызы Зөлфирә Шәйдуллиналар – бүген татар эстрадасының өметле җырчылары.

Клара Әкрәмовнаның үз кызы Айгөл – Мәскәүдә «Орфей» радиосының алып баручысы. Оныгы Сабина Казан сәнгать көллиятендә укып, рәссам-дизайнер булып чыкты. Ә Клара үзе буш вакыты чыгуга, туган авылына – Өнсәгә ашыга. Монда аның үз йорты, үз хуҗалыгы. «Олыгайган саен авыл үзенә тарта. Мин бит авылда үскән кыз. Минем тамырларым биредә!» – ди Клара Хәйретдинова, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы.

Рафис КОРБАН.

Гитлерның апасы – Урал төрмәсендә

